ХАТ ЭЗЕННӘН

Сөт тапшырып алданган авыл кешесенә йөзәрләгән мең сум бурычын кем кайтарыр?

> 5



ЧҮПТӘН – АКЧА

Пыяла шешә белән баеп буламы?

> 6

ГҮЗӘЛ КАЛӘМ

Татарстан матбугаты көнендә – журналистика йөген тартучы хатын-кызлар хакында

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 69 (29036) | Җомга | 19 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

ria.ru

ЫШАНЫЧ ҺӘМ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

«РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: KAZANFORUM – 2023» ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ ФОРУМЫ БАШЛАНДЫ

Догалы эш таркалмас. «KazanForum – 2023» халыкара икътисадый форумы Коръән укып ачылды. Димәк, зур эшкә фатиха бар. Күптән көтелгән, хәзерге вазгыятьтә аеруча әһәмиятле булган, быелдан федераль статус алган чара эш тә, аш та, килешүләр һәм үзгәрешләр дә алып киләчәк. Икътисадый форум эшлекле, мәдәни, спорт, дини чараларга бай. «ВТ» әлеге зур вакыйганың беренче эш көнендә катнашты.

> 2

Ишетми калмагыз

Быел Татарстаннан 470 укучы илкүләм фән олимпиадаларында катнашкан. 40 укучы – җиңүче, ә 211е призер булган. Җиңүче һәм призерлар саны узган елгыдан 14кә күбрәк. Бу күрсәткеч буенча Татарстан инде 11 ел дәвамында иң уңышлы өч төбәк арасына керә. Казанда республиканың иң сәләтле укучыларын һәм аларның укытучыларын хөрмәтләделәр. «Пирамида» комплексында узган чарада «Татарстанның ел укучысы»н да игълан иттеләр. Бу исемгә Казандагы 2 нче лицей-интернатның 10 нчы сыйныф укучысы Роман Моисеев лаек булды.

Татарстан прокуратурасы таләбе буенча 156 кеше машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән. Аларга, сәламәтлегендәге тайпылышлары сәбәпле, рульгә утырырга рөхсәт ителмәскә тиеш булган.

2021 елда да шундый ук тикшерү үткәрелгән. Ул чагында прокурорлар наркологта исәптә торучы 3 мең кешенең машина йөртү таныклыгын суд аша гамәлдән чыгарган.

Прокурорның өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев әйтүенчә, ел башына республикада психик авырулы 13 мең кеше исәптә торган.

Татарстанда 2010–2021 еллар чорында табигатьтә 214 хәтәр күренеш очрагы теркәлгән. Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе мәгълүматлары буенча, бу – елга уртача 18 очрак дигән сүз.

Республикада табигатьтәге хәтәр күренешләр саны – елга 11 очрактан (2017 елда шулай булган) 25кә кадәр (2015 елда) арткан. 2010–2021 елларда бигрәк тә авыл хуҗалыгына кагылышлы куркыныч очраклар (84) күзәтелгән. Шул исәптән 32се – кырау сугу, 14 – туфрактагы корылык, 12шәр очрак – коры җил, явым-төшемнең күп булуы сәбәпле туфракның артык дымлылыгы, 8 – һавадагы корылык, берәр очрак – җирнең иртә туңуы һәм карның иртә ятуы.

Табигатьтәге көйсезлекләр буенча икенче урында – җилгә бәйле куркынычлар (43 очрак). Өченче урында – һава температурасына кагылышлы хәтәрләр.

Министрлар Кабинеты төбәктә климат үзгәрешләренә җайлашу планын 16 майда раслаган. Аның ярдәмендә экологик иминлекне яхшырту күздә тотыла.

Республикада киләсе атна башында +30 градуска кадәр эсселек көтелә. Бу атна ахырында да җылы һава саклана. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә – 20 майда көндез термометрның терекөмеш баганасы +19...+24 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә +5...+10 градус, урыны белән яңгыр. Якшәмбе – 21 майда көндез һава температурасы +22...+27 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +4...+9 градус. Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, киләсе атна башында – 22 һәм 23 майда һава температурасы +24...+30 градуска кадәр җитәчәк. Явым-төшем ихтималы аз.

Исегезгә төшерәбез: бу айда Татарстанда +30 градус булды инде. Майның беренче көнендә республика башкаласында +30,8 градус теркәлде. Бу – рекордлы күрсәткеч.

ЫШАНЫЧ ҺӘМ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

ria.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Икътисад

➤Татарстан белән Иран арасында товар әйләнеше, быел ук икеләтә артып, 40 миллиард долларга җитәргә мөмкин. Бу хакта Иран сәүдә-икътисадый палатасы җитәкчесе Голам Хоссейн Шафеи әйткән.

– Россия һәм Иран мөнәсәбәтләренең чәчәк аткан чоры, бу – моңарчы булмаган хәл. Үзара элемтәләрнең барлык өлкәләре дә җитди үсеш алырга мөмкин, – дигән ул. – Татарстан Иран белән Россия арасындагы хезмәттәшлекне үстерүдә мөһим урын алып торырга мөмкин. Чөнки республика аша, мәсәлән, Идел елгасы ага, ә ул Каспий диңгезенә тоташа.

➤ – Татарстан Россия белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләре арасындагы мөнәсәбәтләрен ныгытырга ярдәм итә. Республика делегацияләренең бу илгә эш сәфәрләре күркәм традициягә әверелде, – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллинның Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең тышкы сәүдә министры Тани Әхмәт Әл Зәйуди белән очрашуында.

Ул май башында узган инвестиция форумында хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алышуларын искә төшерде. Хәзер исә Берләшкән Гарәп Әмирлекләре делегациясе җавап йөзеннән республикага килгән. «Без бергә эшләргә шат. Соңгы елларда күп төрле юнәлешләр буенча хезмәттәшлек итәбез. Безнең өчен Россия – стратегик партнер», – диде дәүләт министры.

➤ – Күпмилләтле һәм күпдинле Россия өчен Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы белән эшләү зур кызыксыну уята, гомумән, Россия һәм бу оешмага керүче күп кенә илләрнең милләтара һәм динара мәсьәләләргә карашы бик якын яки, гомумән дә, туры килә. Бу – элемтәләрне тагын да үстерү, халыкара, парламентара һәм башка мәйданнарда эшне берләштерү өчен яхшы нигез, – диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин халыкара икътисадый форум кысасында узган парламентара хезмәттәшлеккә багышланган чарада. Бүгенге геосәяси шартларда төбәкара һәм парламентара элемтәләрнең әһәмияте тагын да арта, дип билгеләп үттеләр чарада.

Транспорт һәм логистика

➤2022–2030 елларда «Төньяк – Көньяк» проектын үстерүгә инвестицияләрнең гомуми күләме 280 миллиард доллар тәшкил итәчәк. Бу хакта халыкара транспорт коридорын үстерүгә багышланган «түгәрәк өстәл»дә Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин әйтте. Вице-премьер билгеләп үткәнчә, бүгенге геосәяси шартларда әлеге транспорт коридоры аеруча әһәмиятле.

Фаразларга караганда, 2025 елга кадәр әлеге юнәлештә йөк әйләнеше ике тапкыр – кимендә 30 миллион тоннага кадәр үсәчәк. Ә 2030 елда әлеге күрсәткечне 35 миллион тоннага җиткерү бурычы тора. 2021 ел белән чагыштырганда, бу 155 процентка күбрәк.

➤Форум кунакларына өр-яңа «Атом» электромобиленең прототибын күрсәтәләр. «Атом» компаниясенең IT директоры Дмитрий Агиев әйтүенчә, электромобильне күпләп җитештерү 2025 елга тәгаенләнгән. Әлегә әзерлек эшләре алып барыла. Аны җитештерү мәйданчыгы итеп Татарстанны сайларга телиләр. «Казан Экспо»да Рәис Алабуганың «Соллерс» заводында җитештерелүче «Аурус Сенат» машинасына да утырып карады. Интернет-чыганакларга ышансаң, әлеге «тимер ат»ның бәясе 36 миллион сумнан башлана.

Хатын-кызлар мәйданы

Быел «KazanForum» кысасында тәүге тапкыр хатын-кызлар өчен махсус «Хатын-кыз карашы» дигән мәйданчык (трек) эшли. Аны Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе оештырды. Трек катнашучыларын Татарстан Рәисе дә сәламләде. «Безнең форум сездәй гүзәл затлар булганга күрә ун тапкыр матуррак. Ислам дөньясының зур казанышы сез. Хатын-кызларның, аналарның роле артканнан-арта бара. Хәзерге заман хатын-кызлары – сәясәтче дә, эшмәкәр дә, җәмәгать эшлеклесе дә», – диде ул. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да, гүзәл затларның эшенә бәя биреп: «Җитди сорауларны ир-ат үзе генә хәл итә алмый, янәшәдә зирәк хатын-кыз кирәк. Мондый чаралар юкка гына Казанда узмый. Бу – танышу өчен, хезмәттәшлекне дәвам иттерү өчен яхшы мөмкинлек», – диде.

«Хатын-кыз карашы» трегында сәламәтлек, мода, матурлык, хатын-кыз һәм бизнес, үсеш, уңыш турында сөйләштеләр. Форумда 20 илдән 3 меңнән артык хатын-кыз катнаша.

Трек эшчәнлегендә Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән министр урынбасары ярдәмчесе, иминият буенча киңәшче Фатыйма ханым Мөхәммәт Исхак Әл-Әвдхи, Үзбәкстан хатын-кызлар һәм кызлар ассоциациясе президенты Насиба Мирадилова, Камбоджа хатын-кызлар эшләре буенча министрлыкның дәүләт секретаре Мэн Чиндэ ханым, «Миссис Вселенная – 2023» Елена Максимова, «Wildberries» компаниясе генераль директоры Татьяна Бакальчук кебек мәртәбәле шәхесләр катнашты.

Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы

➤«KazanForum» кысасында яшьләр сәясәтенә дә урын бирелә. Әйтик, биредә Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләре яшь дипломатларының VII форумы уза. Чарада 23 дәүләттән килгән дипломатлар халыкара мөнәсәбәтләр турында фикер алышачак. Сүз уңаеннан, алар белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та очрашты. Республика Рәисе ассызыклаганча, яшьләр хезмәттәшлеге – «Россия – Ислам дөньясы» хезмәттәшлеге кысасында төрле чараларны гамәлгә ашыру өчен яхшы нигез булып тора.

➤«KazanForum» кысасында IX Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләре эшмәкәрләре форумы да уза. Иң яхшы проект авторлары Казанда үз эшләрен тәкъдим итә. Быелгы форум финалына 13 илдән 30 проект чыккан. Форум катнашучыларын 20 сәгать лекция, 80 сәгать шәхси һәм төркем белән сессия көтә. Иң яхшы проектларга 10 мең доллар күләмендә акча биреләчәк.

➤«Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы җитәкчесе, Татарстан Рәисе ярдәмчесе Тимур Сөләйманов белдергәнчә, быел беренче тапкыр август аенда Россия һәм Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләреннән балалар өчен халыкара лагерь оештырылачак. Смена Иннополиста узачак. Анда 14–18 яшьлек үсмерләрне һәм яшьләрне көтәләр. Лагерь биш төрле тема буенча эшләячәк: медиа, туризм, мәдәният, дипломатия һәм тотрыклы үсеш максатлары.

➤Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләренә караган 11 дәүләттән җыелган шеф-пешекчеләр Халыкара шеф-пешекчеләр кубогы өчен көч сынаша. Барлыгы 150ләп оста, ит, балык, вегетариан ризыклары пешереп, үз сәләтләрен сынаячак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА,
Эльвира ВӘЛИЕВА

ria.ru

ҮТКӘН АША – КИЛӘЧӘККӘ

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумы кысасында Казан федераль университетында мәдәни мирас турында сөйләштеләр. Чарада ЮНЕСКОның Россия һәм башка илләр үсешендә уйнаган роле хакында фикер алышу булды.

«Татар-информ»

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, мәдәни мирасны саклау һәм үстерү теләсә кайсы төбәк үсешенең нигезендә ята.

– Безнең өчен гаять җаваплы көннәр бара. Кунакчыл Татарстан башкаласына дөньяның 85 иленнән һәм Россиянең 84 төбәгеннән кунаклар килде. Мондый зур ышаныч белдергәннәре өчен ил җитәкчелегенә рәхмәт! – диде ул, кунакларны сәламләп. – Республикада тарихи мирасны өйрәнү һәм саклауга да аерым игътибар бирелә. Ә бу эшнең нигезендә республикада һәм, гомумән, илдә яшәүче күпсанлы халыкларның тынычлыгын, диннәр һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклап калу ята.

Парламент җитәкчесе бүгенге вазгыятьтә менә шушы рәвешле җыелып, аралашуның әһәмиятен дә искәртте. Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, төрле телләрдә фикер алышу дуслыкны һәм бер-беребезгә ышанычны ныгыта гына.

Тарихи һәм мәдәни мирас хакында фикер алышуның чираттагы мәртәбә нәкъ менә Казанда узуы юкка гына түгел. Россия тышкы эшләр министры урынбасары Александр Панкин мөрәҗәгатендә язган сүзләр белән әйтсәк, Татарстан – ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән объектлар саны буенча да, туризм өлкәсендә дә алдынгы урыннарда. Аның сәлам хатын укыганда Россия Тышкы эшләр министрлыгының Күпьяклы гуманитар хезмәттәшлек һәм мәдәни элемтәләр департаменты директоры Александр Алимов бу сүзләрне тагын да куәтләде:

– Татарстанда ике «дөнья» – Көнчыгыш Европа һәм Үзәк Азия кисешә. Монда ничәмә-ничә төрле милләт вәкиле яши. Аларның үзара тату яшәүләре үк күп нәрсә турында сөйли, – диде ул.

15000<	85	84	37	45
катнашучы	ил	Россия төбәге	илче	дипломатия вәкиллеге

РОССИЯ – ИСЛАМСКИЙ МИР KAZANFORUM

ИҢ КҮП КАТНАШУЧЫ ҖИБӘРГӘН ИЛЛӘР

Иран	Азәрбайҗан	Үзбәкстан	Төркия	Малайзия
157	119	106	76	71

ТЫҢЛЫЙЛАР ҺӘМ ЫШАНАЛАР

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Татарстан Республикасы Матбугат көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле газета һәм журнал редакцияләре, телевидение һәм радиокомпанияләр хезмәткәрләре, ветераннар һәм яшь каләм ияләре, басма һәм цифрлы матбугатны әзерләүдә, чыгаруда һәм таратуда катнашучылар! Сезне Татарстан Республикасы Матбугат көне белән ихлас күңелдән котлыйм.

Бүген массакүләм мәгълүмат чаралары көндәлек вакыйгаларны гына яктыртып калмыйча, җәмгыятьнең кәефен, кешеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең, тормыштагы юнәлешләрен билгеләүгә сизелерлек йогынты ясый. Татарстан медиабергәлеге һәрвакыт мәгълүматны объектив бирүе, җаваплылыгы, актив граждан позициясе белән аерылып торды. Шуңа күрә дә ул хаклы рәвештә Россиядә иң югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыкка ия медиабергәлекләрнең берсе булып санала. Килешеп һәм оператив эшләү үрнәген, конкурентлыкка сәләтле, креатив булуын күрсәтә һәм илебез публицистикасының иң яхшы традицияләрен дәвам итә.

Бүгенге заман шартларында республика массакүләм мәгълүмат чаралары, күпгасырлык тарих, мәдәният һәм ватанпәрвәрлек асылын, мәңгелек рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен сакчыл торгызып, мөһим берләштерү ролен уйный. Алдынгы караш ияләре буларак Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары социаль-сәяси тотрыклылыкны тәэмин итүгә саллы өлеш кертә. Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында милләтара тынычлыкны һәм динара татулыкны алга таба ныгытуга ярдәм итә. Дәүләт һәм гади кешенең мәнфәгатьләрен яклап әйткән ныклы сүзегез, шәһәр һәм авылларның, предприятиеләр һәм оешмаларның көндәлек тормышы хакында ачыктан-ачык сөйләшү, тирән эчтәлекле тарихи язмалар һәм актуаль темаларга репортажлар, урынлы тәнкыйть уйларга һәм эшләргә өнди. Ә уртак казанышларыбыз һәм икътисадый уңышларыбыз, каһарманнарыбызның батырлыклары һәм татарстанлыларның игелекле эшләре турындагы язмаларыгыз, уңай кәеф тудырып, бөтен авырлыкларны да җиңеп чыгарга, нык адымнар белән алга барырга ярдәм итә.

Кадерле дуслар! Сезнең хезмәтегез җәмгыятькә бик тә кирәк. Сезне тыңлыйлар һәм сезгә ышаналар. Алга таба да шулай булачагына минем һичбер шигем дә юк. Бүген һөнәри бәйрәмегез белән котлап, сезгә чын күңелдән нәтиҗәле хезмәттәшлегегез өчен рәхмәтемне белдерәм. Татарстан Республикасы һәм, тулаем алганда, Россия Федерациясе хакына шулай эшләгәндә генә без куелган максатларга ирешербез һәм уңышлы булырбыз. Сезнең барыгызга да яңа иҗади проектлар, нык сәламәтлек, тынычлык, бәхет һәм иминлек телим!

НИҺАЯТЬ!

КАЗАННЫҢ УНИКС БАСКЕТБОЛЧЫЛАРЫ ҮЗ ТАРИХЫНДА ТӘҮГЕ МӘРТӘБӘ РОССИЯ ЧЕМПИОНЫ БУЛЫП ТАНЫЛДЫ

vk.com/vtbleague

Бу уңышны узган гасыр ахырыннан бирле көттеләр. УНИКС Европа турнирларында җиңде, Россия Кубогын да берничә мәртәбә отты. Ә менә ил чемпионатында бронза һәм көмеш белән генә чикләнергә туры килде. 2023 елның 16 мае клуб тарихына алтын хәрефләр белән язылачак. «Локомотив-Кубань»ны отып, Казан баскетболчылары, ниһаять, Россия чемпионы булып танылды.

ВТБ Бердәм лигасының ярымфиналында УНИКС узган елгы чемпион «Зенит»ны, «Локомотив-Кубань» исә ЦСКАны откан иде. Финал уеннарының беренчесе Казанда узды һәм кунаклар файдасына тәгәлләнде. Ә аннары өч матч рәттән УНИКС җиңү яулады. Шулай итеп, Казан уенчыларының бишенче очрашуда тарихи уңышка ирешү мөмкинлеге барлыкка килде. Җитмәсә, үз тамашачысы алдында!

Халык белән шыгрым тулган «Баскет холл»да УНИКС матчның башыннан ук өстенлекне үз кулына алды. Очрашуның беренче чиреге – 26:17, икенчесе 58:37 исәбенә тәмамланды. Өченчесендә кунаклар яхшырак уйнады, әмма алтын исен сизгән Казан командасын туктатырлык түгел иде. Очрашу 98:89 исәбенә тәмамланды һәм УНИКС уенчылары, ниһаять, үз дигәннәренә иреште.

Казан клубына 1991 елда нигез салынды. 1998 елдан исә баскетболчылар ул вакытта Татарстанның Милли банкын җитәкләгән Евгений Богачев кул астында чыгыш ясый башлады. 25 ел эчендә УНИКСка күп тренерлар һәм уенчылар килеп китте. Команда Европа турнирларында чыгыш ясады. Иң мәртәбәле ярыш саналган Евролигада көчен күрсәтте. Казан баскетболчылары өч тапкыр Россия Кубогын отты. Бронза һәм көмешләр дистәдән артып китте. УНИКСка махсус аяк чалучылар да булды. Евгений Богачев исә сабырлыгын югалтмады: барыбер алтын көтте. Шуңа күрә 16 май кичендә баш тренер Велимир Перасович һәм хәлиткеч очрашуда 34 очко туплап, турнирның иң яхшы уенчысы булып танылган Ненад Димитриевич белән бергә аны да төп геройларның берсе дип атаулары гаҗәп түгел. «Мин җиңүне юбилейга кадәр махсус көттем», – диде ул.

Язучы сүзе

Ә СОРАУ ТУА...

Марат КӘБИРОВ

Илдә кризис, дибез. Ул кризис дигәнне мин аз гына башкачарак күз алдына китерәм бугай. Эш юк, акча юк, ашарга юк... Тирәяктә ачлар, хәерчеләр... Ләкин илдәге кризис мин күз алдына китергәнчә түгел. Бу – бөтенләй бүтән төрле, башка сыймый торган кризис.

Телевизордан бер җитәкче чыгыш ясый. Зарлана инде, кризис, ди, акча юк, шуңа күп тармакларны ябарга мәҗбүр булдык, ди. Ә кулында биш йөз меңлек сәгать ялтырап-ялтырап китә. Мин инде аннан көнләшмим дә, көнләшергә җыенмыйм да... Ә сорау туа... Ач кеше кыйммәтле сәгать алып такмый бит инде. Йортсыз кеше дә андый сәгать алмый. Мондый нәрсәне кредитка да алмыйлар. Телевизордан чыгыш ясаган бер урта кул җитәкче дә шундый сәгать тагып йөрерлек булгач, нинди кризис соң ул? Ярый, телевизорга ышанмыйбыз, ди инде. Теләсә кайсы җитәкченең гаражына... юк, анда керү килешми, өенә дә, дачасына да килешми... кабинетына килеп керәбез. Теге чүт еламый гына инде, акча юк, кризис, ничек яшәргә белеп булмый... Фәлән йөз меңлек креслосында елардай булып утыра, күз яшьләре тамса, фәлән йөз меңлек өстәле дертләп китәр сыман... Ә сорау туа...

Юк бу илдә берниди дә кризис! Әле без иң соңгы чиккә җитеп, җитәкчеләр кулындагы кыйммәтле сәгатьләрне, кабинетындагы затлы мебельләрне генә сатсак та, бер кайгысыз бер илле ел яши алабыз.

Ярый, җитәкчеләрнең эш башкадыр инде. Гади халык та кимен куймый. Менә син игълан биреп кара: «Арзан хакка икмәк сатам!» – дип, искә алучы да булмаячак. Әгәр ике-өч меңгә ябыктыра торган дару тәкъдим итсәң, сорап шалтыратучыларның чиге юк. Бөтен халык ябыгырга тели. Илдә кризис, ә халык ябыгу чаралары эзли.

Ябыгу өчен иң уңайлы нәрсә бәрәңге икән. Бер гектар итеп утыртасың. Аннан соң утыйсың, күмәсең, утыйсың, кәтмәнлисең, колорадо коңгызын чүплисең, утыйсың, колорадо коңгызын чүплисен, утыйсың... һәм көз җитүгә артык авырлыкның эзе дә калмый. Моны шәһәр кешесе белми торгандыр инде, югыйсә әллә нинди кыйммәт хакка дарулар сатып алмаслар иде. Ә авылныкылар белә һәм моны яхшы куллана. Аларның күбесе бөтен җәйне шулай бакчада уздыра. Мин авылга гадәттә җәй айларында ешрак кайтып йөрим. Шуңа бакчага чыгу белән һәр күршене арт санынннан танып торам. Ләкин күбесенең йөзен күргәнем юк. Шуңа сорау туа... Башка урында очратсам, таныр идем микән?

Һәм иң гаҗәбе – кибеткә чыксаң, үзебездә үскән бәрәңгене таба алмыйсың. Халык җәй буе бакчада, ә бәрәңге... Чынлап та аны ашар яки сатар өчен түгел, ә ябыгу өчен генә үстерәләр бугай.

Кичә тагын кибеткә чыккан идем. Бер сумка ризык сатып алдым. Помидор – Кытайныкы, сарымсак – Израильнеке, редиска – Голландиянеке... Калганын санап тормыйм. Ә сорау туа. Бик беркатлы сорау. Наданлыгымны гафу итәрсез инде, зинһар өчен, тик сорамый да булмый. Бу Россиядә бәяләрдән башка тагын берәр нәрсә үсәме ул?

Сорау туа. Авылга кайтсаң да, сорау туа. Шәһәргә килсәң дә... Гомумән, безнең тормыш сораулардан гына торадыр сыман. Ахмак сораулардан тора. БДИ вакытындагы кебек...

Элек имтиханнар ничек иде?!. Сөенеч, чәчәкләр, аз гына дулкынлану. Хәзер – полиция, сакчылар, камералар, стресс, күз яшьләре. Мин бер нәрсәне аңлый алмыйм. Баланы надан калдыруның сәламәтлеккә зарарсызрак бүтән ысулын табып булмый микәнни соң?

Сорау туу үзе үк яхшы нәрсә инде, бер карасаң. Иркенлекнең, алга, яхшыга омтылуның бер чагылышы. Тоталитар дәүләттә берниди дә сорау тумас иде. Без аны туганчы ук буа барыр идек...

ТӨРЕК ГАМБИТЫ

Узган якшәмбедә социаль челтәрләрдә Истанбулдагы Ататөрек исемендәге аэропорт метросында агрессив төрек милләтчесенең мөселман егете белән конфликтын сурәтләгән видеоролик таратылды. Кемалчы (дөньявилыкны алга сөрүче төрек милләтчеләрен гадәттә шулай атап йөртәләр) сакаллы егетнең тышкы кыяфәтеннән риза түгел, ярсый-ярсый аны сугә, Төркиядән китәргә куша. Һөҗүмгә дучар булган егетнең яңак мускуллары уйный, әмма ул үзен кулда тота. Ләкин материалист тел һөҗүм белән генә чикләнеп калмый, кулны да эшкә җигә. Нәкъ менә шул мизгелдә мөселман егете дә, ниһаять, эшкә керешә: һөҗүм җәһәт кире кагыла, акылын югату дәрәҗәсенә җиткән һөҗүм итүченең арт ягына аяк белән тибәләр һәм вагоннан чыгарып ташлыйлар.

Сюжет Төркиядәге бүгенге вазгыятьне бик яхшы иллюстрацияли: Госманлы хәлифәлеге таркалганнан соң йөз ел дәвамында барган көрәш 14 май сайлавы алдыннан үзенең апогеена килеп җитте. Әрдоган хакимлек иткән соңгы егерме елда үзләренең югалткан позицияләрен акрынлап кайтарып алып килүче мөселманнар белән реваншка омтылган кемалчылар арасында көрәш кызулыгы – температура шкаласының югары ноктасында. 14 май сайлавы алдыннан көчләр чагыштырмасы якынча иллегә-илле тирәсендә формалашты һәм сайлау үлчәү тәлинкәсенең кайсы якка басачагын хәл итәргә тиеш иде. Соңгы йөз елда төрек тарихы якынча болайрак формалашты: Конституция илне дөньяви республика дип игълан итте, дөньявилыкны хәрбиләр гарантияләргә тиеш иде. Ислам ярымтыюлы хәлдә булды. Мәчетләрдә азан төрек телендә әйтелә, бу мәҗбүри иде. Сайлау нәтиҗәсендә хакимияткә килгән мөселманнар үз тарафдарларына аз гына җиңеллек бирә башласалар, вазгыятькә шунда ук хәрбиләр кысыла, идарә итүче мөселман хакимияттән читләштерелә, хәтта төрмәгә дә ябыла иде. Соңгы тапкыр Төркиядә хәрбиләр сәяси исламны мәйданга чыгарган Нәҗметдин Әрбәканны 1997 елның февралендә премьер-министрлыктан китәргә мәҗбүр иттеләр, соңыннан ул төрмәгә дә ябылды. Хәзерге Президент Әрдоган – Әрбәканның шәкерте, 2003 елдан башлап акрын гына, әмма эзлекле рәвештә мөселманнарга ирек бирде: 1997 елда көчләп салдырылган яулыклар яңадан башка менде, сакал үстергән өчен эзәрлекләнү туктатылды. Юк, сез дөрес аңлагыз: Төркия һаман да дөньяви республика булып калуын дәвам итте, сүз хәлифәлекнең торгызылуы турында бармый, шәригать законнары кертелмәде. Социаль һәм икътисадый яктан да ул глобаль капитализмның бер өлеше булып калуын дәвам итте. Әмма җиңелчә генә кайтарылган ирек тә хәрбиләр тарафыннан ислам реваншизмы буларак кабул ителде. 2016 елда алар янә бер тапкыр элекке тәртипләрне тулысынча кире кайтару ниятеннән хәрби түнтәрелеш ясарга омтылдылар, әмма Әрдоганның популярлыгы югары, мөселманнар үзләренең өлешчә кайтарылган хокукларын югалтырга теләмиләр иде. Халыкның көчле яклавы астында Әрдоган үз постын саклап калды, хәрбиләр түнтәрелделәр. Фетнәне оештыручы югары хәрби дәрәҗәдә утыручылар төрмәләргә ябылды. Бу – вазгыятьнең бик кыска сурәтләнеше, билгеле. Төрек җәмгыятендә бихисап су асты агымнары, үзара каршылыкта торган бик күп көчләр бар. Милли каршылыклар да җитәрлек. Менә шул көчләр һәм агымнар 14 май көнне хисап ясарга тиешләр иде: гадел көрәштә җиңүченең ачыклануы көтелде. «Гадел» дип без шартлы рәвештә генә алабыз, билгеле. Әрдоган сайлау комиссияләренә административ басым ясамый, бу Төркия шартларында мөмкин дә түгел. Фальсификацияләр турында тавышлар чыккалады чыгуын, ләкин алар фейклар иде. 14 май көнне Әрдоганга җиңү өчен 0,6 процент тирәсе генә тавыш җитмәде. Административ ресурсны куллану мөмкин булса, ул тавышларны гына «ясау» берни дә тормас иде. Хәзер икенче тур өчен әзерлек һәм көрәш бара. Гамәлдәге лидерның өстенлеге бәхәссез булса да, җиңү гарантияләнмәгән.

Быелгы төрек сайлавы – төрек сайлавы гына түгел. Ул глобаль дөнья өчен әһәмиятле вакыйгага әверелде. АКШ һәм Көнбатыш Европа илләре ачыктан-ачык үзләренең Әрдоганга дошман позицияләрен белдерделәр. Европа журналларында аның образын каралткан, вәхшиләштергән портреты төрле ракурсларда күпләп басылды. Төрек сайлавына тышкы тыкшыну чамадан ашты һәм чикләрне белмәде. Грек телевидениесендә тапшыруны алып баручы эфирда ачыктан-ачык: «Әгәр Әрдоган хакимлектә калса, аны сайлаудан соң ук атарга кирәк», – дип белдерде. Күз алдыгыза китерегез: берәр мөселман репортеры Көнбатыш лидерларына бәйле рәвештә шундый сүзләр әйтсә, нинди гауга чыгар иде. «Әл-Җәзира» каналының алып баручысы Әхмәд Мансур дөрес әйтте: «Хәлифәт җимерелгәннән соң 100 ел эчендә Көнбатыш беренче тапкыр Төркиядәге сайлауны Көнбатыш белән ислам арасында сугыш буларак карый», – диде.

Көнбатышлыларның төрек сайлавына аеруча зур игътибар бирүе аңлашыла, чөнки Әнкара соңгы вакытларда үзен бәйсез тота. Төрек дәүләтенең башбирмәслеге аның хәрби һәм технологик куәте үсүгә нигезләнә. Моңарчы да ил НАТОдагы иң көчле икенче армия тотучы дәүләт буларак бәяләнә иде. Соңгы берничә елда ул үзенең хәрби сәнәгатен нык үстерде, Көнбатыш коралына мохтаҗлыгын киметте генә түгел, үзе корал экспортлаучы державалар сафына басты. Андый дәүләтнең кем ягында булуы принципиаль әһәмияткә ия. Шуңа күрә Көнбатыш илләре төрек сайлавына үзләрендәге сайлауларга караганда да зуррак игътибар иттеләр. Мөмкин булса, Төркиягә тавыш бирү өчен үз сайлаучыларын җибәрерләр иде.

Оппозиция лидеры Кылычдароглу сайлауда җиңгән очракта Төркиянең тышкы сәясәтен 180 градуска үзгәртәчәген, Көнбатыш белән аркадашлык итәчәген белдерде, Россия – Украина конфликтында Украина ягына басачагын да әйтте. Бу позициядән караганда, Россия Әрдоган җиңүен теләргә тиеш иде. Мәскәүдә үзләрен бик тыйнак тоттылар, төрек сайлавына ачыктан-ачык тыкшыну сизелмәде. Шулай да Кылычдароглу сайлау алды көрәшендә Мәскәү кулы уйный дип тавыш куптарды. Кремльдә ул аткан ташны кире кактылар. Россиянең сәяси элиталары арасында оппозицион төрек лидерына теләктәшлек белдерүчеләр бар иде шулай да.

Сайлау алды көрәше пычрак технологияләрсез генә булмады. Оппозицион кандидатларның берсе Мөхәррәм Инҗәне порнографик видео персонажы буларак халык игътибарына чыгардылар. Ул үз башын кисеп, башка кешегә куйганнар дип акланды, видеоны фейк дип атады, әмма дистанциядән төште. Чит илдәге төрек гражданнары ул вакытта инде тавыш биреп өлгергәннәр иде. Инҗә бюллетеньдәге исемлектә калдырылды барыбер һәм 0,5 процент тавыш җыйды.

Тавышларны санаган төн – 14 майдан 15енә каршы сәгатьләр бик киеренке булды. Рәсми төрек агентлыклары Әрдоганның алда баруын расласалар да, оппозиция чыганаклары моның киресен әйтте: Кылычдароглу җиңеп бара, диделәр. Әле тавышларның яртысы да саналмаган иде, Истанбул һәм Әнкара мэрлары: «Сезгә 13 нче Президент Кемаль Кылычдароглу исеменнән мөрәҗәгать итәбез», – дип халыкка чыктылар. Иртәнгә Кылычдароглуның Әрдоганнан 5 процент тирәсе генә калышуына карамастан, икенче тур кирәклеге мәгълүм булды.

Икенче тур нинди генә нәтиҗә белән тәгәлләнмәсен, дөнья сәясәтенең шахмат тактасында төрек гамбиты башлануга китерергә мөмкин. Көнбатышта аны нәкъ менә шундый позициядән торып кабул итәләр дә инде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

НАМУС ЭШЕ

Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил авылы халкыннан борчулы хат килеп ирешә. «Ике ай сөт тапшырган өчен акчабызны ала алмыйбыз. Кайбер кешеләргә заводның 200әр мең сум бурычы бар. Сөт бәяләре болай да төшеп бетте, анысын да бирмичә тилмертәләр», – дип язылган әлеге хатта. Авыл халкының гозере буенча юлга кузгалдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авылда сыерлар саны ел саен 8–10 башка кими», – ди Мамадыш-Әкил авылы халкы.

Гаделсезлек

Алар безне җыелышып, мәчет каршында каршы алды.

– Безнең авыл халкы сөтне гомер-гомергә шул тәртиптә тапшырган. Акчасын түләүдә бервакытта да тоткарлыклар булмады, – дип башлады сүзен авылның аксакалы Гомәр Хәялиев. – Тик узган елда августның икенче яртысыннан сөт өчен түләми башладылар. Без инде, сабыр итик, булыр, дип, сөтне тапшыруны дәвам иттердек. Тик акчаны сентябрь өчен дә түләмәделәр. Шуннан соң башка сөт җыючыбыз икенче бер завод белән килешү төзеп, шунда тапшыра башлады.

Узган елның августыннан алып 3 октябренә кадәр тапшырган сөт өчен акчаны әлегә кадәр ала алганнары юк икән. Сөт җыючы Наил Гыйбадуллин башта, авырыйм, дигән. Аннан соң, акча булачак, дип өметләндергән, хәзер, халык сүзләре буенча, ул алардан качып йөри. Сентябрьдән исә сөтне Наил Гыйбадуллинның шоферы Фәрит һәм аның хатыны Гөлфинә Әдиятуллина җыя башлаган.

Сөт җыючылар чималны арадашчы Илдар Галимов дигән кеше аша Югары Ослан районының Русское Макулово авылындагы сөт заводына тапшырган. Нәтиҗәдә «Югары Ослан» җәмгыяте Мамадыш-Әкил авылындагы егермеләп кешегә 600 мең сум акча тиеш. Әйтик, Хәялиевләр – 37 мең сум, Азат Галиев 32 мең сум акчасыннан коры калган. Сигез сыер савучы Петр исә ике айга 198 мең сум табышыннан колак каккан.

– Ул вакытта без дүрт сыер сава идек. Хәзер икегә калдырдык, чөнки мал асрауның файдасы калмады, – ди Азат Галиев, ачынып. – Сөтне болай да арзанга тапшырабыз. Анысын да бирми азаплагач, күңел ничек үссен ди?! Мал асрау өчен, сәгать иртәнге 4тә аяк өстендә булырга кирәк. Сөт акчасы – авыл халкының төп табышы. Безнең карап торган хәләл керемебез ул.

Кызганыч, авыл хуҗалыгы продукциясе беркемгә дә кирәкми. Ул вакытларда сөт бәясе 24 сумнан 22 сумга төште. Хәзер менә бөтенләй 15 сум түлиселәр икән. Авылда сыер саны елдан-ел 8–10 башка кимеп бара. Быел унбиш сыерга азайды. Бүген 200 хуҗалыктан көтүгә 43 сыер чыга. Татарстан Рәисе үз чыгышларында сыер санын бетермәскә өнди, әллә аның да сүзе үтмиме? Бу очракта да сүз берничә йөз мең сум акча турында гына түгел, ә миллионнар турында бара. Ник шуңа бер чара күрә алмыйлар?

Зыян күрүчеләр арасында 70 яшьлек Гөлсинә Әшрәпова да бар.

– Авылны үстерәбез, диләр. Шушы да буламы үстерү? Моны күреп торган яшьләр авылда ничек калсын? Улым гаиләсе белән безнең янда яши. Моннан соң алар авылда калырмы? Моңа кадәр, тукта, сабыр итик, үзебезнеке, дия-дия сыер тоттык. Яшебез шактый булса да, ничек тә тырыштык. Акчасы булсын дип, сөтне бозау авызыннан өзеп алып тапшырдык. Сөтен дә, акчасын да күрмәдек, – ди Гөлсинә Әшрәпова.

Бу хәлләрне авыл халкы, чыннан да, бик авыр кабул иткән. Сәбәпләрен эзләпэзләп тә, очына чыга алмаганнар алар.

– Илдә болай да тыныч түгел. Инде бу эшләр халык арасында тагын да зуррак ризасызлык уятыр өчен махсус эшләнә микән әллә, дип тә шикләнәбез. Без – авылга тамырыбыз белән береккән кешеләр. Инде шуңа да балта белән кизәнәләр, – дип ачынды Гомәр Хәялиев.

«Улымның гаебе юк»

Сөт җыючы Наил Гыйбадуллин күрше Татар Танае авылында яши булып чыкты. Аның үзен күреп сөйләшер өчен, шул авылга бардык. Тик үзе Казанга хастаханәгә китү сәбәпле, безне аның әнисе Динә ханым каршы алды. Нинди эш белән йөрүебезне аңлаткач, «Үзем дә бик яхшы сөйлим мин сезгә», – дип, белгәнен аңлатып бирде.

– Улым авырый минем. Гел хастаханә юлын таптый. Узган елның 4 сентябрендә хастаханәгә кереп яткач, сөтне Гөлфинә белән Фәрит Әдиятуллиннар җыя башлады. Сөт Илдар Кәримович аша китә иде. Хәзер турыдан-туры эшләми дип беләм, барысы да – килене контролендә. Илдар Кәримович аңа кадәр дә күбрәк кинәшче ролендә иде. Төп эшләрне уллары Марат белән Наил башкарды, – диде Динә Гыйбадуллина.

Аның сүзләренчә, заводның Наил Гыйбадуллинга һәм Әдиятуллиннарга 1 млн 300 мең сум бурычы бар. Наил абый берничә тапкыр акча сорап та барган булган.

– Баш хисапчы: «Мин берни дә белмим», – дип җилкә генә җыера. Завод директорлары да җаваплылыктан качмакчы була, – диде Динә Гыйбадуллина.

Нинди дә булса аңлатма өмет итеп, без дә Илдар Галимовка берничә көн дәвамында шалтыраттык. Тик телефонны гына алучы булмады. Һәм тиз генә алачак та түгел, ахрысы. Хәлләрне аңлатып бирәсе, халыкка ярдәм итәсе урында шыпырт кына утырып торуны сайлаган булып чыкты ул. Хәер, безгә әйтүләренчә, ул гына түгел, башка гаилә әгъзалары да беркем белән дә элемтәгә кермиләр.

Заводның үзенә дә чыктык. Җитәкчеләре белән тоташтырырга теләмәсәләр дә, телефондагы ханым оешманың әлеге вакытта эшләвен һәм спред (атланмай аналогы) җитештерүләрен әйтте.

– Түләү исәп-хисап счеты буенча алып барылмый, алар ябык. Акча да юк. Шуңа күрә әлегә халыкка бурычларны кайтару мөмкинлеге юк. Киләчәк өчен җавап бирә алмыйм, – дип чикләнде ул.

«Югары Ослан» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 1998 елдан бирле эшли. Соңгы бер ел эчендә аңа карата 18 суд эше ачылган. Без соратып алган мәгълүматлардан аңлашылганча, быелның февралендә Салым федераль хезмәте «Югары Ослан» агрофирмасын банкрот дип тану буенча дәгъва биргән. Заводның салым бурычлары – 151 миллион сум. Берничә суд утырышы булган да инде. Чираттагысы 3 июльгә билгеләнгән.

– Бу хәлләрдән хәбәрдар без, тик оешма банкротлыкка чыккач, берни дә эшли алмыйбыз, – диде Яшел Үзән районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Таһир Җиһаншин да. – Вакытында салым түләмәгәннәр икән, димәк, алар – намуссыз кешеләр. Бу эш белән прокуратура шөгыльләнә. Әлеге вакытта бинаны кемдер арендага алып торып эшли. Ахыр чиктә барыбер ябылачак ул завод. Сөт җыю да, тапшыру да, эшкәртү дә – бизнес, без аны контрольдә тотарга тиеш тә түгел.

1,5 млн сум бурыч

Әлеге оешма бер генә авыл халкын ярык тагарак алдында калдырмаган. Намуссыз эшмәкәрләрдән Яшел Үзән районының башка авыл халкы да зыян күргән. Апас, Балтач районнары кешеләре дә заводтан зур күләмдәге акча таләп итә. Әйтик, Яшел Үзән районының Рус Әҗәле авылыннан Гүзәл Бикмуллина да 3 сыер савып саткан сөт акчасын ала алмый. Заводның аңа 67 мең сум бурычы бар.

– Безгә дә узган елның август – сентябрь айлары өчен түләмәделәр. Сөт җыючыбыз «була, була» дигән сүздән башканы белми. Ләкин кайчан була ул – билгесез, – диде Гүзәл апа.

Белгеч фикере

Булат ЗАКИРОВ, юрист:
– Кешеләр алданмас өчен, сөт җыючы белән сөт тапшыручы арасында килешү булырга тиеш. Аны төрлечә, әллә нинди катлаулы документлар төземичә генә, сату-сатып алу килешүе белән дә эшләргә мөмкин. Ай ахырында сөт тапшыру турындагы актка кул кую да җитә.

Кайбыч районының Борындык авылында яшәүче Мөдәррис Галиуллин да авыр хәлдә калган. Аңа Макулово заводы 1,5 млн сум акча тиеш. Ул да арадашчы Илдар Галимов аша эш йөрткән.

– Бу хәлләрдән минем үземә дә бик авыр, – диде ул. – Берникадәр акчаны халыкка үземнең өлештән дә тараттым, ләкин ул кадәрне ничек биреп бетерим? Кемгәдер – 60 мең, кемгәдер – 80, кемгәдер 100әр мең сум тиешмен. Сөтне ике фермер да тапшыра иде миңа. Берсенә – 400 мең сум, икенчесенә 100 мең сум бурычым бар. Илдар Кәримович суд булганнан соң, счетларын ачарга тиешләр, шуннан соң акчаны кайтарачаклар, дип әйтә килде. Әле дә булса өметләнәм. Халыкны да шулай дип тынычландырам.

Сабак өчен

Тырышлыгы белән генә түгел, усаллыгы, уҗатлыгы белән дә дан казанган авыл халкы үзләре дә кул кушырып утырмый, билгеле. Гаделлек эзләп, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка да хат язганнар. Әлеге мәсьәләдә тагын бер кыенлык бар: сөт җыючы белән сөт тапшыручылар арасында килешү юк. Шунлыктан, Югары Ослан районы прокуратурасы хатыннан аңлашылганча, дөреслек эзләп йөрү, бурычларны даулауның да файдасы булмаячак.

– Без килешү төзергә каршы түгел, тик сөт җыючылар ризалык бирми, – дигән фикерне дә ишеттек халыктан.

Юрист Булат Закиров аңлатуынча, бурычларны җыеп алу – бик катлаулы эш.

– Оешма банкрот дип табылган очракта, акча оешмадагы җиһазларны сатып кайтарылырга тиеш. Сатарлык берние дә юк икән инде, бурычлар шул килеш һавада эленеп калырга мөмкин. Ләкин банкротлыкка чыгару – озакка сузыла торган процесс, – диде белгеч.

ТОТ ШЕШӘҢНЕ!

Чүптән – акча! Соңгы арада пыяла банка һәм шешә тапшыручылар саны арткан. Икенчел чимал кабул итүчеләр шулай ди. Совет чорындагы кебек, шешәне кибетләргә мәҗбүри тапшыруны кире кайтарырга тәкъдим итүчеләр дә бар хәтта. Пыяла шешә тапшырып, акча эшләп буламы? Бу эш белән кемнәр шөгыльләнә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшелнең кадерсез чагы

Рәсми саннарга караганда, пыяла шешәгә чүплектә таркалырга бер миллион (!) елга кадәр вакыт кирәк. Аяк асты ватык пыялага әйләнмәсен өчен нишләргә соң? Иң беренче уйга килгәне – аны яңадан эшкәртүгә тапшырырга, әлбәттә. Интернеттагы игъланнар сайтында пыяла савыт җыю турындагылары әллә ни күп түгел.

– Бу эш белән өч елга якын шөгыльләнәбез, – ди Биектауда урнашкан икенчел чимал кабул итү пункты хезмәткәре Артур. – Тулаеу нигездә үтә күренмәле һәм коңгырт төстәге пыяла шешәләр җыябыз. Ярты литрлы бер шешә бәясе уртача 60 тиен тора. Яшел төстәгесен дә алып килергә мөмкин. Әмма бушлай. Шешәне төсенә карап аеру чималны яңадан эшкәртү белән шөгыльләнүче заводларның лабораторияләре эшенә бәйле. Яшел, зәңгәрсу, шәмәхә төстәге шешәләрне үзебездә туплап барабыз да, заводлар кабул итә башлагач, шунда озатабыз. Татарстанда мондый сәнәгать юк. Чималны күршетирә төбәкләргә җибәрәбез. Юл хакы шешә җыю бәясенә дә тәэсир итә.

Интернет мәгълүматларына ышансаң, Татарстанда буш пыяла шешә өчен иң кыйммәт бәяне «Экосбор+» оешмасы тәкъдим итә. Мәсәлән, биредә үтә күренмәле пыяланың бер тоннасы 2400 сум тора.

– Пыяланың теләсә нинди төрен: буш шешәләр дә, тәрәзә пыялалары да җыябыз. Иң мөһиме – алар чиста, юылган булырга тиеш. Капкачлы һәм башында бөкрасы булган шешәләр кабул ителми. Җыелган чималны ил күләмендә пыяланы яңадан эшкәртү белән шөгыльләнүче заводларга озатабыз. Мәсәлән, Воронеж белән хезмәттәшлек итәбез. Удмуртиянең Можга шәһәрендә пыяланы яңадан эшкәртәләр. Үтә күренмәле һәм коңгырт төстәге шешәләргә ихтыяҗ зуррак, – ди оешма хезмәткәре. – Данәләп шешә тапшырып кына әллә ни баеп булмый, әлбәттә. Әлегә мәсьәлә иң беренче чиратта табигать турында кайгыртучыларны борчый. Икенчел чималны тапшыру пунктларына кадәр барып йөрергә теләмәүчеләр өчен, Казанның төрле урыннарында махсус контейнерлар да урнаштырдык. Биредә пыяла шешәләрне бушлай калдырып китәргә мөмкин. Махсус хәрби операция башланганчы, аена 150 тоннага кадәр пыяла тапшыра идек. Быелтыр тармак тынып калды. Хәзер кабат пыяла тапшыра башладылар. Дөрес, әлегә күрсәткечләр ике тапкыр кимрәк. Алга таба бар да элеккеге хәленә кайтыр, дип өметләнәбез. Кафе-рестораннардан да күпләп буш шешә китерә башладылар.

Бу эш республиканың кайбер районнарында да алып барыла.

– Пыяла шешәләрне халыктан да, оешмалардан да кабул итәбез, – ди Әгерҗе кулланучылар оешмасы рәисе Рөстәм Ваһапов. – Әзер чималны күрше Удмуртиягә төяп китәләр. Ярты литрлы бер шешә бәясе якынча 50 тиен тора. Узган айда районда 2,5 тонна пыяла җыелган.

Тәмне дә саклый, җылыны да

Татарстанда пыяла савыт җыю һәм яңадан эшкәртү эше җайга салынганмы? Бу сорау белән республикадагы берничә министрлыкка мөрәҗәгать иттек. Тик төгәл җавап бирүче булмады. Икътисад белгече Илдус Сафиуллин әйтүенчә, базарда пыяланы пластмасса шешә кысрыклап чыгарды. Шуңа күрә аны яңадан эшкәртү дә онытылды.

– Кирәкле чимал илгә читтән кайтарыла. Моңа бәйле кыенлык юк. Тик мәсьәләнең икенче ягы бар: 2030 елга кадәр ил күләмендә полигоннарга чыгарылган чүпне икеләтә киметү бурычы тора. Шуңа күрә иртәме-соңгы пыяланы да яңадан эшкәртә башларга туры киләчәк. Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, Россиядә елына 5 миллион тонна пыяла җитештерелә, яңадан эшкәртелгәне исә 1 миллион тоннага да тулмый. Хәтерләсәгез, күптән түгел ил Хөкүмәтендә кибетләргә шешәне совет чорындагы кебек мәҗбүри тапшыруны кире кайтарырга тәкъдим иттеләр. Бу да шуңа бәйле, минемчә.

Пыяла шешәгә ихтыяҗ бар. Кукмарада җитештерелүче лимонад турында ишетмәгән кешеләр сирәктер.

– Ни өчен нәкъ менә пыяланы сайладыгыз, дип еш сорыйлар. Мондый шешәдә эчемлекнең тәме яхшы саклана, – ди «Забава» лимонад заводы директоры Ильвир Руфин. – Без лимонад, тархун, мохито, газлы һәм газсыз сулар җитештерәбез. Заводта пластмасса шешә гомумән юк. Пыяла шешәне Ижаудан кайтартабыз. Моңа бәйле берниндидә кытлык юк. Әзер продукцияне Казан, Лаеш, Чаллы, Кукмарада сатабыз. Ярты литрлы бер шешә лимонад 45 сум тора. Суларны пластмасса шешәдә чыгарып карадык, тәме югала. Үзегез уйлап карагыз: өйдә компотны элек-электән өч литрлы банкаларда ясыйлар бит. Берәү дә биш литрлы пластмасса су савытына тутырып куймый. Заводта көненә 1,5–2 мең шешә эчемлек җитештерәбез. Бу да чик түгел. Киләчәктә Кукмара лимонадын ил күләмендә сатарга телибез.

Ильвир Руфин сүзләренә караганда, алар үзләре саткан пыяла шешәне кабул итү һәм яңадан эшкәртүне җайга салу мәсьәләсен өйрәнеп караганнар. Тик гамәлдәге кануннар моңа туры килеп бетми, дип аңлатты җитәкче.

Яшел Үзән районының Әйшә авылында яшәүче Азат Гатауллин исә буш пыяла шешәләрне нишләтергә икәнен белә. Дистә елдан артык төзелештә эшләүче егет шул рәвешле мунча идәнен җылыткан.

– Пыяла шешә – бик арзанлы һәм сыйфатлы төзелеш материалы, – ди Азат Гатауллин. – Ул җылылыкны яхшы саклый. Мунчада агач идән астын яңадан пыяладан җәйдем. Моның өчен ябык шешәләр кирәк. Ник дисәң, шешә эчендә һава йөрсә, ул җылыны сакламаячак. Җил уйнап, тавыш кына чыгарып утырачак. Идән җәйгәндә, шешәләрне аска каратып куйсаң, яхшырак. Бер квадрат метр мәйданга якынча 70–80 шешә китте. Аларны никадәр тыгызрак тезсәң, шулкадәр җылырак булачак. Хәзер гараж нигезен эшләү өчен пыяла шешә җыям. Танышларым да бу хакта белә. Кунакка килгәндә бер дә буш килмиләр *(көлә)*. Ныклыгы ягыннан пыяла шешә таштан калышмый. Өстенлекле яклары да шактый: мондый нигез еллар узу белән дә утырмаячак, ул дымга бирешми, череми.

КАЗАНДА ПЫЯЛА САВЫТ ҺӘМ ШЕШӘ ТАПШЫРУ КҮПМЕ ТОРА?

Төре	Бәясе (бер данә)
Үтә күренмәле шампан шәрабы шешәсе	2 сум
Караңгы төстәге шампан шәрабы шешәсе	2 сум
Аракы шешәсе	2 сум
Борып яба торган аракы шешәсе	1 сум
Сыра шешәсе	60 тиен
Шәраб шешәсе	1 сум
Коньяк шешәсе	1 сум
3 литрлы банка	10 сум

(бәяләр интернеттагы игъланнардан алынды)

Икмәк өчен

Башкаладагы социалистик көнкүреш музее директоры Рөстәм Вәлиәхмәтов әйтүенчә, совет чорында пыяла шешәнең эченә караганда тышы кыйммәтрәк торган.

– Чимал кытлыгына бәйле рәвештә, элек сөт шешәсен тапшырган акчага – бер кирпеч ак ипи, ә лимонадтан бушап калган шешә бәясенә бер кирпеч арыш икмәге сатып алырга мөмкин булган. Туңдырма, кинога балаларга билет та шулкадәр үк торган. Ягъни кибеттән товар сатып алганчы ук, аның күпмедер бәясен кире кайтарып булачагын белеп эш иткәннәр. Шуңа күрә олысы да, кечесе дә шешә җыеп тапшырган. Ишегалларында да, паркларда да буш пыяла савытлар аунап ятмаган. Шешәләрне кибетләрдә яки кибет янындагы махсус пунктларда кабул иткәннәр. Әлеге күренеш узган гасырның 60–80 нче елларында бик популяр була һәм 90 нчы елларына кадәр дәвам итә. Бүген исә ул чордагы шешәләр музей киштәләрендә саклана. Ул вакытта шешәнең төрләре хәзерге кебек күп булмаган. Музейда сөт, баллы су һәм шәраб шешәләрен күрергә мөмкин. Киштәләрдә шундый егермеләп пыяла савыт бар, – ди җитәкче.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Гөлфинә ЗАРИПОВА, эколог:
– Көз алдына китерегез: табигатьтә пыяла шешәдән дә озаграк батарейкалар гына таркала. Шуңа күрә әлеге төр материал әйләнә-тирә мохиткә зыян китерми, дип фикер йөртүчеләр ялгыша. Ватык пыяла кисәкләре кешеләр һәм хайваннар сәламәтлегенә куркыныч тудыра. Моннан тыш, мондый туфракта зарарлы микроорганизмнарга үрчү өчен уңайлы мохит барлыкка килә. Җирнең уңдырышлылыгы кими. Шуңа күрә буш шешәләрне чүпкә атканчы, җиде кат уйларга кирәк. Югыйсә сез ташлаган балалар боламыгы банкасы әле сезнең фәләненче буын оныкларыгызга да барып җитәчәк.

26 майда сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан ГАРИФУЛЛИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ничек берләштерергә?

Бакчачылык ширкәтендә минем ике җир участогым бар. Янәшә урнашсалар да, документта алар ике территория булып санала. Шуларны ничек берләштерергә икән? Бакчага кагылышлы тагын бер соравым бар. Безнең ширкәттә комплекслы кадастр эшләре үткәргәннәр. Әмма мин кайбер нәтиҗәләрдән риза түгел. Хәзер участокның чикләрен яңадан тикшертә аламмы?

Минзилә ВӘЛИЕВА.
Чаллы

Галина Галиуллина, Росреестрның Татарстан идарәсе матбугат җитәкчесе:
– Кадастр нәтиҗәләреннән риза булмасагыз, башта сезгә шул эшне җиренә җиткерергә кирәк. Реестр хаталарын төзәтер өчен, әзер ызанлау планы белән бергә гариза язып, күпфункцияле үзәккә тапшырыгыз. Чөнки участокларны берләштерү барышында әлеге документларның төгәл булуы шарт. Аннан инде берләштерү эшенә дә тотына аласыз. Моның өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Берләштерелгән участок Җирдән файдалану кагыйдәләренең минималь һәм максималь чикләүләренә туры килергә тиеш.

Табибны кайдан табарга?

Мин Казанның Киров районындагы «Салават Күпере» микрорайонында яшим. Күптән түгел операция ясаттым. Даруларым беткәч, невропатологтан тагын яздырып алырга кушканнар иде. Башта, талон алыр өчен терапевтка керергә кирәк, диделәр. Кердем. Ә невропатологка 31 майда гына эләгергә мөмкин икән. Белгечләр шимбә көнне атнасына бер генә килеп китәләр, диделәр. Мин бит алай озак көтә алмыйм. Тернәкләнү өчен даруны берөзлексез эчәргә кирәк. Мондый очракларда нишләргә соң?
Безнең микрорайонда ул поликлиникаларны нишләп ясамыйлар икән? Югыйсә яңа төзелгән йортларның беренче катлары буш тора бит.
Гомумән, бездә яшәү өчен бернинди шартлар да юк. Телефон сафтан чыкса, шуны да төзәтә алмый миңгерәп йөрисең. Азык-төлек алырга ярминкә дә оештырмыйлар. Югыйсә халык артканнан-арта бара бит инде. Йортларның яңаларын салып кына торалар. Анысы яхшы инде, әлбәттә. Тик өлкән яшьтәге кешеләр Казанга барып йөри алмый бит. Әле менә 9 Май бәйрәме үтте. Без – сугыш чоры балалары. Быел миңа 87 яшь тула. Бер ярдәм дә юк. Югыйсә, заманында таякка эшләп, бөтен салымнарны түләп яшәдек бит. Шуларны искә алып, бик моңсуланып утырдык. Газетаны яздырып алам. Һәр санын көтеп алам. Бергә җыелышып укыйбыз. Яшьләр дә бик кызыксына. Бик яратабыз.

Минҗиһан МӨХӘММӘТШИНА.
Казан, «Салават Күпере» микрорайоны

Редакциядән. Җавап алу өчен, бу сорауны Казан шәһәренең Киров районы хакимиятенә юлладык. Әлегә җавап килмәде. Килеп җитүгә, сезне дә таныштырырбыз.

Корыган яфраклардан котылыргамы?

Аптыраганнан шалтыратам инде. Яз җиткәч, бакча җиләкләрен корыган яфраклардан арындыра торган гадәтем бар. Ә күршемнең фикере башкача. Шунда өзелеп төшә дә ашлама булып ята ул, ди. Җиләккә килгәндә, икебезнеке дә бер чама уңыш бирә. Күршем дөрес сөйлиме икән, шуны беләсе иде. Тагын бер нәрсә турында гел бәхәсләшеп алабыз. Аның ике теплица булу сәбәпле, берсенә – кыяр, икенчесенә помидор утырта. Миңа, бер генә булгач, икесен дә бергә утыртырга туры килә. Алар бер-берсенең энергиясен суыра дип, гел шуңа бәйләнә.

МӘҮЛИДӘ апагыз

Лилия Дәминова, һәвәскәр бакчачы:
– Чыннан да, җиләкне чистарту буенча каршылыклы фикерләр яшәп килә. Хәтта галимнәр арасында да. Әмма күпьеллык практика күрсәткәнчә, яз көне җиләкне корыган яфраклардан чистартырга кирәк. Ни өчен дисезме? Корыган яфраклар арасында авырулары да шактый. Алар кызыл төстә була яки таплар белән каплана. Сәламәт яфрак яшел төстә генә була. Эш алдыннан кайчы яки секаторга да дезинфекция ясарга онытмагыз. Корыган яфракларны җыеп яндырыгыз. Былтыргы мыекчаларны да алырга онытмагыз. Үсемлек, аларны үстереп, энергиясен әрәм-шәрәм итеп утырмасын. Тәмле, сусыл җиләкләр ашарга насыйп булсын!

Ә кыяр белән помидорга килгәндә, күршегезнең фикере дөрес. Бәлки, мөмкинлегегез булса, кыярны борыч белән бергә утыртырсыз. Тик бер шарты бар: башта кыярны утыртыгыз, 1–2 көн үткәч, борычка чират җитәр.

Кайтаваз

«АРТЫК ТАМАК» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР
Менә ул – гыйбрәтле ачы язмыш. Моны укыгач, безгә зарланырга ярыймы инде? Бик уйландыра торган язмыш. Сәламәтлек сезгә.

Рауза Дәминова

* * *

Адәм баласы барысына да түзә...

Фирия ЛАТЫЙПОВА-КУДАШЕВА

* * *

«ТҮБӘН КАМАДА 22 ЯШЬЛЕК АНА ЯҢА ТУГАН БАЛАСЫНЫҢ МӘЕТЕН ТУГЫЗ КӨН БУЕ БАЛКОНДА ЯШЕРЕП ТОТКАН»
Үтерерлек булгач, ник тапкан ул баланы? Баланың ни гаебе бар соң? Үстерәсең килмәгәч, детдомга бирергә иде. Оятсыз хатын. Мин булсам аның урынында, җир убылып, җир тишегенә керер идем.

Нурия СИБГАТУЛЛИНА

* * *

Берәүгә дә бу хатын урынында булырга язмасын!

Ләйсән САФИНА

Ялга китә аламмы?

Икенче бала тугач, бала карау буенча декрет ялын ирем алырга булды, чөнки минем эш шактый төшемлерәк иде. Әмма озак та үтми, оешмабызда эш тукталып, аннан китәргә туры килде. Хәзер ирем эшкә чыкса, декрет ялына мин үзем китә аламмы икән? Тагын бер соравым бар. Хезмәт хакын түләмичә генә ялга җибәрү дөресме ул?

Гөлсирә ӘХМӘТШИНА.
Казан

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
– РФ Хезмәт кодексының 255 нче маддәсе буенча әни кеше, ә 256 нчы маддәсе буенча әти кеше бала карау буенча декрет ялына китә ала. Бу вакытта аның эшләмәве шарт булып тора. Декрет ялын чиратлашып та алырга мөмкин. Әмма эштән китүнең нигезле сәбәбе булырга тиеш. Сезнең очракта оешма ябылган. Димәк, законда каралганча, җитди сәбәп бар дигән сүз. Дәүләт пособиеләре бирелүнең тәртибе һәм шартлары буенча, ул кем декрет ялын рәсмиләштерә, шуңа бирелә.

Икенче сорауга килгәндә, РФ Хезмәт кодексының 128 нче маддәсе буенча, хезмәт хакын түләмичә генә ялга җибәрү хезмәткәрнең гаризасы нигезендә генә мөмкин. Эш бирүче шулай ук мондый ялны гариза нигезендә пенсионерларга, инвалидларга бирергә тиеш. Әгәр хезмәткәр гариза язмый икән, эш бирүченең аны бушлай ялга җибәрергә хокукы юк. Бу, әлбәттә инде, оешмада яки предприятиедә эш тукталган очракка карый.

Хезмәт кодексының 157 нче маддәсе нигезендә эш бирүче гаебе белән эш тукталса, ул хезмәткәренә уртача хезмәт хакының өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган күләмен түләргә тиеш. Әгәр дә инде эштән туктауга хезмәткәр дә, эш бирүче дә гаепле булмаса, акча вазыйфаи окладның өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган күләмендә түләнә. Кайчагында эшнең ни сәбәпле тукталганын билгеләп булмаска да мөмкин. Мондый вакытларда суд органнары ярдәмгә килә. Хезмәткәрне үзара килешү буенча башка эшкә дә күчереп торырга мөмкин. Әгәр дә сәбәпләр саллы булса (янгын, фаҗига), бер айга башка эшкә күчереп тору өчен ризалык кирәкми. Әмма түбән квалификацияле эш булса, хезмәткәр барыбер ризалыгын бирергә тиеш.

Фикер

Машина ник кире кайта?

Тиздән Сабантуйлар җитә. Татарстаннан читтә дә ел саен үткәрелә алар. Зурракларына, көрәштә җиңүчегә дип, машина да алып баралар. Тик... аны үзләре белән алып кайтып та китәләр. Бер яктан караганда дөрес кебек бу. Җиңүче, гадәттә, Татарстанныкы була бит. Әмма ерак җиргә хөрмәт итеп алып баргач, аны шул төбәктәге көрәшчегә калдырсалар, әйбәтрәк булыр иде, минемчә. Татарстаннан килгән бүләк дип, горурланып сөйләрләр иде.

Тагын бер баш миен бораулап торган фикерем бар. Инде менә ничә еллар Айдар Хәлим белән Фәүзия Бәйрәмованы Тукай премиясенә тәкъдим итәләр һәм... төшереп калдыралар. Минемчә, әлеге шәхесләр бик лаеклы бу премиягә. Аларны хөрмәт итәргә кирәк. Гомумән, Тукай премиясенә кандидатны билгеләр өчен халык арасында сайлау үткәрү дөресрәк булыр иде.

Фәнис МӘҮЛИЕВ.
Мөслим

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

22 май | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.30 «КАЙДА СИН?» Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.30 «Трибуна «Нового века» 16+
19.00, 00.25 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Карл Фукс, которого любили все 16+
00.50 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телефильм 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 18.50 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Михаил Гаврилов, Сергей Пускепалис, Агния Дитковските. «ТРЕЙДЕР» (S) 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ольга Будина, Андрей Чернышов, Ирина Купченко, Нина Усатова, Татьяна Васильева, Светлана Немоляева, Лариса Удовиченко, Сергей Степанченко. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+
03.45 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лучшие из лучших» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 15.10 Новости
07.05, 18.40, 21.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Хоккей. Чемпионат мира. Чехия – Швейцария. Трансляция из Латвии 0+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.20 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
15.15 «Громко». Прямой эфир
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Канада – Норвегия. Прямая трансляция из Латвии
19.25 Футбол. Чемпионат Италии. «Рома» – «Салернитана». Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Эмполи» – «Ювентус». Прямая трансляция
23.55 Футбол. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Уругвай – Ирак. Прямая трансляция из Аргентины
02.00 Новости 0+
02.05 Хоккей. Чемпионат мира. Австрия – Венгрия. Трансляция из Финляндии 0+
04.15 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Японии 0+

НТВ

04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Олег Штефанко, Анна Большова, Алексей Булдаков. «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «БОРЩИ» (S) 16+
22.15, 00.00 «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
00.55 «БЕЗДНА» (S) 16+
03.30 Детектив «ПЕТРОВИЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.05 «Давай разведёмся!» 16+
09.05 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Оковы» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «УБИЙСТВО НА ТРОИХ» 16+
19.00 «С ЧИСТОГО ЛИСТА» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.35 «Порча». «Оковы» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «КОЛЫБЕЛЬ НАД БЕЗДНОЙ» 16+
05.55 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «КАДЕТЫ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55, 01.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Восточный рубеж». 1-я серия 12+
12.35 «Победоносцы». Документальный сериал 16+
13.25, 15.15 «НЕСЛУЖЕБНОЕ ЗАДАНИЕ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.55 «ВЗРЫВ НА РАССВЕТЕ» 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва за Россию». Документальный сериал. «От Кинбурна до Фокшан. Суворов против Юсуф-паши». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Денацификация Франции» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ИГРА БЕЗ ПРАВИЛ» 12+
02.45 «Александр Феклисов. Карибский кризис глазами резидента». Документальный фильм 12+
03.30 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
03.55 «АНАКОП». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

23 май | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Оркестр «Ренессанс» 6+
00.50 «Соотечественники». София Губайдуллина. Прикосновение к душе 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Вечерняя игра» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 21.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телефильм 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.00, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ТРЕЙДЕР». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Ольга Будина, Андрей Чернышов, Ирина Купченко, Нина Усатова, Татьяна Васильева, Светлана Немоляева, Лариса Удовиченко. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Ольга Красько, Олег Алмазов, Александр Ратников, Сергей Мухин. «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+
03.45 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лучшие из лучших» 12+
07.00, 10.00, 15.10 Новости
07.05, 15.15, 18.40, 22.40 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Хоккей. Чемпионат мира. Дания – Швеция. Трансляция из Финляндии 0+
12.15 Хоккей. Чемпионат мира. Германия – Франция. Прямая трансляция из Финляндии
14.40 «География спорта. Уват» 12+
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Швеция – США. Прямая трансляция из Финляндии
19.25 Мировой футбол. Обзор 0+
20.15 Хоккей. Чемпионат мира. Швейцария – Латвия. Прямая трансляция из Латвии
23.35 Специальный репортаж 12+
23.55 Футбол. Чемпионат мира. Молодёжные сборные. Аргентина – Гватемала. Прямая трансляция из Аргентины
02.00 Новости 0+
02.05 Хоккей. Чемпионат мира. Канада – Чехия. Трансляция из Латвии 0+
04.15 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция с Бермудских островов 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сериал «БОРЩИ» (S) 16+
22.15, 00.00 Детективный сериал «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
00.55 Детективный сериал «БЕЗДНА» (S) 16+
03.25 Детектив «ПЕТРОВИЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Порча сухоцвета» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «Голоса ушедших душ» 16+
15.10 «МАРАФОН ДЛЯ ТРЁХ ГРАЦИЙ» 16+
19.00 «ГРЫМЗА» 16+
23.25 «Понять. Простить» 16+
00.40 «Порча» 16+
01.10 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «КОЛЫБЕЛЬ НАД БЕЗДНОЙ» 16+
05.55 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «АНАКОП». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55, 01.10 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Восточный рубеж». 2-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва за Россию». Документальный сериал. «От Рымника до Измаила. Суворов против Юсуф-паши» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ПЯДЬ ЗЕМЛИ» 12+
02.25 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
03.50 «Легендарные самолеты. Ту-22. Сверхзвуковая эволюция». Документальный фильм 16+

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«ТАИФ» компанияләре төркеме коллективы, улы

МОРАТОВ Марсель Равил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Моратов Равил Фатыйх улының авыр кайгысын уртаклаша.
Равил Фатыйхович, якын кешегезне югалту ачысын ничек тә җиңелрәк кичерергә язсын. Марсель Равил улының – тормышта актив позициядә торган изге күңелле кешенең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҖЫЛЫТКАННЫ ЯРАТМЫЙ

Колак шаулый, йөрәк авырта, бил сызлый... Ни эшләргә? Сәламәтлеккә бәйле сораулар һәрвакыт туып тора.

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА җавап бирә.

vk.com

:: Колак шаулау нәрсәсе белән куркыныч?

– Колак шаулау бик күп чирләр турында кисәтә ала. Гадәттә, кеше кан басымы, температурасы күтәрелгәндә, баш миенең кан тамырлары зарарланганда (атеросклероз), колак авырлары вакытында шуннан зарлана. Колактагы шау инсульт, мигрень турында да кисәтә ала. Шуңа күрә колакта гүләү, сызгыру, кыштырдау, пышылдау, шыгырдауны хәтерләткән тавышлар ишетелсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Авыртуны баса торган даруларны көн саен эчәргә ярыймы?

– Бик нык авыртуга түзеп, аны дару эчмичә генә үткәрергә маташу – зур хата. Галимнәр, андый чакта баш миендәге нерв күзәнәкләре үлә, дип ышандыра. Шуңа күрә баш авыртканда, теш сызлаганда авыртуны баса торган дару эчәргә кирәк. Әмма чама хисен дә югалтырга ярамый. Авыртуны баса торган мондый даруларны 7–15 көн дәвамында кулланырга рөхсәт ителә. Шуннан да артса, алар зыянга эшли башлый. Кешедә йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгу, тромб өзелү куркынычы арта, күзе начар күрә башларга мөмкин. Күпкә китсә, авыртуны баса торган дарулар бавырга да бәрә.

:: Остеохондрозны йөрәк авыртудан ничек аерырга?

– Аларны, дөрестән дә, бик еш бутыйлар. Йөрәк авыртканда, кеше конкрет кайсы җире авыртуын төртеп күрсәтә алмый. Остеохондроз вакытында исә кеше кайсы төше авыртканын төгәл белә. Йөрәк авырту кул, муен, теш казналыкларына бәрергә мөмкин. Ул кешенең нинди халәттә торуына бәйле түгел. Остеохондроз вакытында исә авырту бер урында гына борчып тора. Кеше билгеле бер халәттә яки ниндидер хәрәкәт ясаганда, мисал өчен, иелгәндә авырту көчәюне сизә. Андый чакта, гадәттә, умырткалык буыннары авырта.

:: Шикәр җыерчыкларны арттыра, диюләре дөресме?

– Әйе, баллы яратучыларның йөзе, гадәттә, вакытыннан алдан җыерчыклана. Биттә тимгелләр дә пәйда була ала. Шикәрне эшкәртү өчен организм бик зур күләмдә кальций, В витамины, фосфор сарыф итә. Ул аларның барысын да сөяк һәм мускуллардан ала. Шул рәвешле кешенең сөякләре зәгыйфьләнә, иммунитеты какшый, остеопороз пәйда булырга мөмкин.

:: Даими рәвештә баш авыртудан интеккән кешенең хәтере начарлана, диләр. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Кан басымы уйнаган кешеләр баш авыртудан аеруча еш интегә. Андый чакта кан тамырлары киеренке хәлдә эшләргә мәҗбүр. Кан басымы бер төшү, бер менү аркасында, баш миендә хәтергә тискәре йогынты ясаучы урыннар пәйда була. Холестерин арту сәбәпле, кан әйләнеше бозылган кешеләрнең дә хәтере начарлана. Шуңа күрә вакытында табибка күренеп торырга кирәк.

:: Бил авыртканда җылыта торган мазьлар сөртергә ярамый, ул яман шеш китереп чыгарырга мөмкин, диләр. Бу сүзләр хакмы?

– Бил авыртканда аны, дөрестән дә, җылытырга ярамый. Ник дигәндә, җылылык тәэсирендә нерв җепселләре тагын да катырак ялкынсыначак. Бу исә – бил авырту да көчәячәк дигән сүз. Сызлаган урынны җылыткач, бил авырту яман шешкә әверелә дигән сүзләр дөреслеккә туры килми. Һәрхәлдә, бу уңайдан бернинди фәнни аңлатма да юк. Ә менә бил авырту үзе яман шеш билгесе була ала.

ДИЛӘРӘ ШАҺИЕВАДАН КИҢӘШЛӘР

→ Иң беренче чиратта, вакытында йокларга ятып, вакытында торырга кирәк.
→ Шоколад, каһвә, чикләвек, кызыл шәраб кебек продуктлардан баш тарту хәерле.
→ Көн дәвамында утырып эшләүчеләргә дөрес итеп утырырга кирәк. Арка – туры, компьютер мониторы күз биеклегендә булырга тиеш. Аяклар 90 градуска бөгелгән, куллар өстәлдә булса, яхшы.
→ Баш авыртмасын, дисәң, аякны аяк өстенә куеп утырырга да киңәш ителми. Бер сәгать утыргач, гәүдәне яздырып, йөреп килергә дә онытмагыз.
→ Бүлмәне даими рәвештә җилләтеп торуның да файдасы зур.

Киңәш-табыш

Алмаш-тилмәш кирәк

Бала самокатта көненә 2 сәгатьтән дә озаграк йөрергә тиеш түгел. Табиб ортопед-травматолог Елена Плигина шулай дип кисәтә. «Баланың мускулларына зыян килмәсен өчен, ул самокатта йөргәндә һәр 10–15 минутка бер тапкыр этенә торган аягын алыштырып торырга тиеш. Башта бер аяк белән этенсен, аннары икенчесе белән. Баланың кулына самокат тоттырыр алдыннан аңа иң элек әнә шул кагыйдәне аңлатырга кирәк. Самокатта дөрес йөрмәсә, баланың мускулларында асимметрия башланачак. Бу исә аның үсешенә тискәре йогынты ясарга мөмкин», – ди табиб.

Шифалы

ТАМАК АВЫРТКАНДА

Бер чәй кашыгы тозга бераз гына лимон согы, бер чәй кашыгы бал, ярты чәй кашыгы гәрчич һәм 100 мл җылы су салабыз. Шуның белән көнгә берничә тапкыр тамакны чайкатырга кирәк.

Үзем сынадым

Җырчы Резидә ШӘРӘФИЕВАдан файдалы рецепт

Иммунитетны ныгытабыз.

2 аш кашыгы балга 2 чәй кашыгы тутырып куркума салабыз, 1 чәй кашыгы төелгән кара борыч өстибез. Бергә болгатабыз. Бу катнашманы су белән йотасы түгел, чәй кашыгы очына алып кабып, авызда эрегәнче тотасы.

Табигать даруханәсе

Тузганак дәвасы

Бакчаларда, басу-кырларда ут янып утырган тузганак чәчкәләренең шифасын тоеп калырга кирәк! Белгечләр шулай дип киңәш итә. Әлләр никадәр авырудан дәвасы бар аның.

✓ Тузганак тимер, фосфор, калий, А һәм С витаминнарына, шулай ук аксым кушылмаларына бай. Аның согында сидек кудыручы тараксацинның ачы матдәсе бар. Тузганак шикәр чире, үт куыгы һәм бавыр авыруларына, авитаминоз, анемиягә каршы көрәшергә ярдәм итә.

✓ Хәлсезлектән дә булыша. Ике чәй кашыгы вакланган тузганак тамырын һәм үләнен 1 стакан кайнар суда 1 сәгать төнәтеп сөзегез. Шуны ашарга 30 минут кала, көнгә дүрт тапкыр чирек стакан эчегез.

✓ Йокысызлыктан, нерв киеренкелегеннән, витамин җитмәүдән дә тузганак ярдәмгә килә. Яңа әзерләнгән тузганак согын (50 мл), ашарга 30 минут кала, көнгә ике тапкыр өч атна дәвамында эчегез.

✓ Хәтер начараюдан һәм атеросклероздан тузганак тамырыннан яңа гына әзерләнгән сокны һәм дәге кайнатмасын бергә-бер (1:1)

күләмдә кушып, ашарга 30 минут кала, көнгә өч-дүрт тапкыр 50 мл эчегез.

✓ Бөердә һәм сидек куыгында таш, ком һәм башка авырулар булганда, симергәндә, эч күпкәндә, эч катканда, суалчаннардан котылу өчен төнәтмәне түбәндәгечә ясап эчәргә кирәк: вакланган 2 чәй кашыгы тузганак тамырын 1 стакан суга салып, 8 сәгать салкын урында тотып сөзегез һәм көнгә берничә тапкыр эчегез.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

МАЙ – МӘШӘКАТЬЛЕ АЙ

Бакчачының да, игенче кебек үк, майның бер көне ел туйдыра, дигән мәкальне ялгыш та исеннән чыгармаган көннәре. Ай ахырында тагын нәрсәләргә игътибар итәргә?

vk.com

Бакчачы-блогер Людмила КУДРЯВЦЕВА укучыларыбызны борчыган сорауларга җаваплар бирде.

? Помидор үсентеләрен ачык туфракка чыгарып утыртырга вакыт җиткәндер инде дип уйлыйм. Аларны яңа урынга тизрәк җайлаштыру, «стресс»тан коткару юлларын беләсе иде.

Зөлфия ХӘСӘНОВА. Әлмәт

– Үсентеләрне кояшлы көндә утырткан очракта, тизрәк яңарып китсеннәр өчен, аларга берничә көнгә күләгә ясап торырга (үсенте тирәли агач ботаклары урнаштырырга яки тукыма булмаган материал белән каплап куярга мөмкин) киңәш итәм. Бу чыныкмаган томатлар өчен бигрәк тә кирәк. Чәчәккә бөреләнгән икән, утыртуга Эпин-Экстра (5 л суга 1 мл) бөркергә тырышыгыз. Фитогормон яңа шартларга җайлашуны бермә-бер җиңеләйтә. Су сибүгә килгәндә, утыртканнан соң бер атна-атна ярым чамасы узганнан соң гына (ә май башларында утырткан очракта – бөтенләй дә 2–3 атна узгач кына) сибү яхшы. Үсенте тамырларының яңарып китүе өчен, утыртканда, чокырына салган су да бик җитә. Суны күп сипмәү тамырлары ныгуга китерә.

? Күп кенә бакчачылар томат үстерүчеләргә йод эремәсе кулланырга киңәш итә. Аны кайчан һәм ничек дөрес итеп кулланырга?

Гүзәл ШӘКҮРОВА. Баулы районы

– Йод эремәсе, чыннан да, помидор үсентеләрендәге күп кенә чирләргә каршы көрәшү өчен бәһаләп бетергесез санала. Аны 10 литр суга 10 тамчы йод, бер литр эремчек суы (яки әчегән сөт) һәм ярты чәй кашыгы бор кислотасы өстәп ясыйлар. Барысын бергә болгатып, помидор үсентеләренә бөркиләр.

Болай эшләгәндә, помидор уңышы мулдан булачак, үсентеләр фитофтора белән дә чирләмәячәк. Эремәне куллануга килгәндә, беренче тапкыр аны помидор үсентеләре чәчәк аткач бөркиләр. Бер-ике атнадан бу эшне яңадан кабатлыйлар. Гомумән, үсентеләр чәчәктә утырганда, 4–5 тапкыр бөркергә кирәк. Йод эремәсен шулай ук кыяр, баклажан ише культураларга карата да кулланырга була.

? Суган һәм сарымсакның кыяк очлары саргая. Нишләргә икән?

Лилия НУРГАТИНА. Саба районы

– Әче туфракта шулай булырга мөмкин. Аны тиешле нормага китерү өчен, 10 литр суга 3 аш кашыгы кальций селитрасы өстәп, һәр үсенте төбенә берәр стакан эремәне сибеп чыгарга кирәк. Яисә 2 стакан көлне бер чиләк суда эретеп, үсемлекләр төбенә сибәргә.

Туфракта азот җитмәгән очракта исә суган кыяклары – саргылт, ә очлары ак төскә керә. Бу очракта кыякларга кичен нашатырь спирты эремәсе (10 литр суга 3 аш кашыгы исәбеннән) бөркергә мөмкин.

? Виктория түтәлләрен пычкы чүбе белән мулчалаган идем. Аның зыяны булмасмы икән?

Вероника НИКИТИНА. Питрәч районы

– Пычкы чүбе дымны яхшы саклый. Аны түтәлгә җәеп кенә куюдан бернинди дә зыян юк. Җиләкләрне җыйганнан соң, пычкы чүбен компостка алып куярга яки, өстенә үсенте тонатмасе, тирес сибеп, рәт араларын шуның белән бергә казып чыгарга кирәк.

Укучы киңәше

КАРТ КУАКНЫ ЯШӘРТЕП БУЛА

Крыжовник куагы җимеш бирми башласа, сәбәбе картаю булырга мөмкин. 15 еллык куакның җимеш бирмәве – нормаль хәл. Әмма аны яшәртеп җибәрергә мөмкин. Моның өчен өч ел рәттән куакның өчтән бер өлешен төбеннән үк кисеп торырга кирәк. Болай эшләгәндә, янә җимешләре белән куандыра башлаячак ул.

Кайбер ботаклары гына крыжовник бирмәсә, шуларын гына төбеннән кисү дә җитә.

Григорий СЕМЕНОВ. Балык Бистәсе

ЧҮПНЕ АШЛАМАГА ӘЙЛӘНДЕРӘБЕЗ

Гаиләбез белән кукурузга мөкиббән без. Шуңа күрә һәр ел саен аны бакчада утыртмыйча калганыбыз юк.

Көзгә таба түтәлдә байтак кына кукуруз сабаклары тырпаеп кала. Аларны ыргытмыйбыз, ә яндырабыз. Сабаклардан минераль матдәләргә гаять бай көл кала.

Көлне чиләккә җыеп, язын җиләк куакларын, күпьеллык чәчәкләрне шуның белән туклаңдырабыз. Нәтиҗәсе искиткеч!

Роза ХИСМӘТУЛЛИНА. Түбән Кама

Исеңдә тот!

Жалюзи юу сере

1 литр суга 1әр аш кашыгы савыт-саба юу сыекчасы һәм 9 процентлы уксус исәбеннән, эремә ясыйбыз. Кулга катмарлы (махровый) иске оекбаш яки бияләй киеп, эремәдә чылатабыз һәм жалюзиның һәр пластинасын юабыз. Шуннан соң кондиционер салынган чиста су (1 литр суга 1 чәй кашыгы) белән сөртеп алабыз.

Ә бик нык пычранган жалюзины ваннада савыт-саба юу сыекчасы салынган суда 30–40 минут тотабыз. Аннан инде душ лейкасыннан агып торган җылы су белән чайкатабыз.

Тәмле булсын!

«ЯЗГЫ КАЛЕЙДОСКОП» САЛАТЫ

Рәмзия ГАФИЯТУЛЛИНА рецепты

Витамин, минерал, аксым һәм клетчаткага гаять бай булган кыр сарымсагыннан (черемша) витаминлы язгы салат ясап карарга ашыгыйк!

Кирәк: *1 бәйләм кыр сарымсагы, 1 помидор, 1 кыяр, 1 баш суган (шәмәхәсе булса әйбәтрәк), 4–5 редис, тәменчә тоз һәм борыч, 1 аш кашыгы майонез (майсызрак), 1 аш кашыгы каймак.*

Кыякларны юып, озынча итеп турыйбыз яки кул белән өзгәлибез. Помидор, кыяр, редис һәм суганны вак-рак кисәкләргә турыйбыз. Тоз, борыч өстибез. Майонез һәм каймак катнашмасы салып болгатабыз.

Матурлык сагында

МАЙЛЫ БИТ ӨЧЕН

Биттәге күзәнәкләре киңәеп, яңак, ияк, борын һәм маңгай тирәләре майланып-ялтырап торучыларга менә дигән битлек ясау ысулын тәкъдим итәбез.

Бер аш кашыгы каркаде чәе яфрагын кайнар суда пешеклибез. Йомшаргач, суыннан алабыз. Суына төшкәч, һәр яфрагын 10 процентлы сөт өстенә (сливки) манып, бер-бер артлы биткә куеп чыгабыз. 10–15 минут тоткач, җылы су белән юып алабыз.

Бит тиресендәге май бизләрен рәткә керту, күзәнәкләрне тарайту, битнең тәсен яхшырту өчен шундый битлекне бер тапкыр ясау да җитә. Ә инде аена ике тапкыр ясаганда, бит тиресендәге кара һәм ак ноктралардан да котылырга мөмкин.

Белеп тор!

Иң файдалы дөге

Кибетләрдә ярманың, шул исәптән дөгенең нинди генә юк! Элек, аны-моны уйлап тормастан, нинди туры килсә, шунысын сатып ала идем. Хәзер исә парландырылганын гына сайлыйм.

Беренчедән, изелми. Шуңа күрә гөбәдия, бәлеш, пылау ише ризыклар пешерү өчен бик уңайлы. Икенчедән, күптән түгел генә бер журналдан ярманың нәкъ менә шушы төренең сәламәтлек өчен иң файдалысы булуы турында укыдым. Белгечләр аңлатуынча, теләсә кайсы бөртекнең иң файдалы өлеше – тышчасы. Тик шомартканнан соң андагы витаминнар һәм микроэлементлар калмый диярлек.

Парландырылган дөге исә, исеменнән күренгәнчә, пар белән эшкәртелә. Бу очракта тышчасындагы файдалы микроэлементлар бөртекнең эченә үтеп керә.

Сүз уңаеннан, мондый дөгедә шикәр микъдары да аз икән. Димәк, кандагы шикәр микъдары күтәрелүдән шикләнүчеләр өчен дә – әйбәт ризык.

Анастасия МИХАЙЛОВА. Балык Бистәсе

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН МӘҢГЕЛЕК

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чөнки ул сезгә үлемне искәртер», – ди. Фанилыкта яшәгән өебез генә түгел, бакыйлык турында искәртеп торучы мәңгелек йортыбыз да тәрбиягә мохтаҗ. Зиратны, каберләрне чистартканда нәрсәләрне истә тотарга кирәк?

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Каберлекне чистартканда өстенә бассаң, гөнаһ буламы?

– Каберлекне чистарткан, чардуганны буяган вакытта аның өстенә басмыйча гына эшләү мөмкин булмаса, моның зыяны юк. Ә мөмкин булса-булмаса кабер өстеннән йөрү, анда басу, аны мәсхәрә итүдән сак булырга кирәк. Динебездә каберләргә, зиратка зур игътибар бирелә. Рәсүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтендә зиратка кергәч әйтелә торган сәлам догасы да бар. Аның бер хәдисеннән аңлашылганча, Рәсүлебез бер сәхабәнең ике кабер арасында йөргәнен күргәч, аңа хәтта аяк киемен салырга кушкан. «Мөселманның каберенә басуга караганда минем өчен үткен кылычка яисә утлы күмергә басу хәерлерәк булыр иде», – дигән ул.

:: Каберлекне чистарткач чыккан чүпне ни эшләтергә? Аны зираттан читкә чыгарып, чүплеккә түгәргә ярыймы?

– Мондый чүпне зираттан читкә чыгарып чүплеккә түгәргә ярый. Чардуган буяганнан калган буяу савытларын, каберне чистартканнан соң калган чүпләрне, әрвахларны кимсетерлек итеп, юл өсләрендә, кабер кырыйларында калдырмасак иде. Кабер, зират ул – безнең мәңгелек йорт. Якыннарыбызның, газизләребезнең исән чакта кадерләрен белергә өйрәник. Бик кыйммәтле чардуган, артык зәвыклы ташлар куюдан бернинди хасият юк. Мәрхүмнәргә дога кирәк. Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, шушы эшләрдә исрафтан да саклансак иде, диясе килә.

:: Чардуган буяганнан соң калган буяу, пирчәткә, пумала кебек әйберләрне өйгә алып кайтырга ярамый, шунда зиратта калдырырга кирәк, диләр. Бу ни өчен шулай дип әйтелә икән?

– Моның дәреслеген раслаучы дәлилләр юк. Бу – ырым-шырымга ышану гына. Әгәр кеше бер литрлы буяуның аз гына өлешен тоткан икән, аны ташлап булмый бит инде. Бу исраф булачак. Ә исраф – шайтанның дусты. Шуңа күрә зиратка алып барган әйберне кире өйгә алып кайтуның бернинди куркынычы да юк. Чардуганның төсен яңартканнан соң калган буяуны өйгә алып кайтырга шикләнәбез икән, аны берәр кирәкле җиргә тапшырсак, бүләк итсәк, хәерлерәк булыр.

:: Кабер өстендә зур булып үсеп утырган агачларны кисәргә ярыймы? Кискән очракта ул агачны ни эшләтергә?

– Динебездә кабер өстенә агач утыртуның да нигезе бар. Рәсүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм зиратка барган вакытта, ике кабер янына туктап: «Менә бу ике кабер әһеле газапта. Алар үз гөнаһларын кечкенә дип уйлады. Берсе сүз йөрткән, икенчесе итәгенә бәвеле тигәнен белә торып, аны алыштырмаган өчен», – дигән. Шуннан ул агач ботагын икегә бүлеп, берсен – бер, икенчесен икенче кабергә кадап куйган. Пәйгамбәребез: «Ул аларга җиңеллек бирер, шушы агач ботаклары аларга дога кылып торыр», – дигән. Кабер өстенә агач утырту гадәте шуннан килгән дип санала. Ләкин бу агач еллар узган саен үсә, зурая. Алар ава, кабер өсләренә төшә, чардуганнарны имгәтә. Шуңа күрә кабер өстендә үсеп утырган андый агачларны кисәргә ярый. Аның бер гөнаһы да юк. Һәр зиратның кискән агачларны куя торган урыны була. Аны билгеле бер оешмаларга алып барып ягучылар да очрый. Болар бар да рөхсәт ителә.

Гөлнара Зиннәтуллина

:: Кояш баегач, зиратка керергә ярамый, диләр. Зиратны, каберлекләрне кояш баеганчы чистартып өлгермәсәң, эшне туктатып, икенче көнне дәвам итәргә кирәкме? Әллә чистарту эшләрен кояш баегач дәвам итсәң дә зыяны юк түгелме?

– Рәсүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кояш баю, ахшам вакыты җитү белән балаларыгызны урамга чыгармагыз, үз яныгызга җыегыз», – дигән. Ник дигәндә, ул вакытта шайтан үзенең җеннәрен җир өстендә явызлык кыларга җибәрә. Шуңа күрә зиратка да кояш баеганчы бару хәерлерәк булыр. Әмма кергән очракта да бу гөнаһ саналмый. Зиратны кояш баеганчы чистартып бетерергә өлгермәсәң дә, эшне туктатырга кирәкми. Караңгыга калганчы, эшне тәмамлау хәерле.

:: Хатын-кыз зиратка үзе генә кереп, каберлекне чистарта аламы?

– Хатын-кызның зиратка баруы турында сөйләгәндә, галимнәрнең фикере аерыла. Аларның берише – хатын-кызга зиратка барырга ярый, икенче берләре – бу мәкрүһ (эшләмәсән, хәерлерәк булган гамәл), өченчеләре исә хатын-кызга зиратка бару тыела, дигән фикердә. Шуңа күрә хатын-кыз, зиратка үзе генә кереп, каберлекне чистарта ала, әмма анда ире белән барса, хәерлерәк булыр, дибез.

:: Чардуган алыштырганда искесен ни эшләтергә? Аны тимер итеп тапшырып, сатарга ярыймы? Кабер ташын алыштырсаң, аның искесен ни эшләтергә?

– Чардуганны алыштыргач, аның искесен тимер итеп тапшырырга, сатарга ярый. Бу акчаны яңа чардуган алганда кушарга яисә хәерле икенче эшкә кулланырга мөмкин. Кабер ташын алыштырганда искесен ташларга мөмкин. Моннан бернинди зыян да килмәячәк.

:: Авылларда зиратны өмә ясап җыештыралар. Бу өмәгә, җае килсә дә, бармаучылар очрый. Зират чистарту кебек күмәк, изге эштән шул рәвешле читтә калу гөнаһмы?

– Бер хәдистә: «Аллаһы Тәгаләдән булдыра алган кадәр куркыгыз. Ул калдырган сөннәтне мөмкин кадәр үтәгез», – дигән юллар бар. Мөселман ул – җәмгыятьтә файда китереп яши торган кеше. Рәсүлебез тагын бер хәдисендә: «Сезнең иң хәерлегез – башкаларга файда китергәнегез», – диде. Шуңа күрә ислам дине ул – бердәмлек дине. Шуңа күрә зиратны чистарту өчен җыелган өмәдә мөмкинлегең була торып та катнашмау хәерле гамәл саналмас. Зират, кабер – үлемне искә төшереп, ахирәт турында уйландыра торган урыннар. Шуңа күрә шушы мәңгелек йортларыбызга игътибарлы булыйк. Бер-беребезгә ярдәм итик, үлемне искә төшереп, дөньяви гөнаһлардан, хәерсез эшләрдән ерак торыйк.

Гыйбрәтле кыйсса

Кем ул кеше?

Карт арыслан улларга ята икән, баласын чакырып алган да: «Мин урманның патшасы булдым, кешедән башка бернәрсәдән дә курыкмадым, балам, кешедән саклана күр», – дип кисәткән.

Баласы: «Әнием, кеше нинди була ул?» – дип сораган. Арыслан җавап бирә алмый үлеп киткән. Арыслан баласы кешене эзләп чыгып киткән. Бара торгач, бик ямьсез, бик куркыныч тавыш ишеткән. «Мөгаен, бу кешедер», – дип, тавыш килгән якка киткән. Барып җитсә, ишәк акырып тора икән. Арыслан баласы аңа сәлам биргән һәм: «Син кеше түгелме?» – дип сораган. Ишәк: «Юк, мин кеше түгел, мин – ишәк», – дип җавап биргән. «Син кешегә охшаганмы?» – дип кызыксынган арыслан баласы. «Охшагандыр, – дигән ишәк. – Минем бик күп кешеләрнең бер-берсенә ишәк дигәннәрен ишеткәнем бар».

Арыслан баласы алга таба киткән. Күрә: каршысына бик зур бер буар елан килә, аңа да сәлам бирә: «Син кем, кеше түгелме?» – дип сорый. Елан: «Юк, мин кеше түгел, мин – елан», – ди. «Син кешегә охшаганмы соң?» «Охшаган, – ди елан. – Мин бик күп ирләрнең хатыннарына елан дигәнен ишеткәнем бар».

Бераз баргач, арыслан баласы нәкъ апара уртасында аунап ятучы дуңгызны күрә. Аңа да шул ук сорауны бирә: «Син кешегә охшаганмы?» «Минем бик күп хатыннарның ирләренә дуңгыз дигәннәрен ишеткәнем бар. Шулай булгач охшаганмындыр», – ди дуңгыз.

Аптырый арыслан баласы: «Үзе озын, үзе пычрак, үзе ямьсез тавышлы, үзе куркыныч, бу нәрсә икән инде?» – дип. Шулай аптырап торганда, күзе агач башындагы маймылга төшә. Аңа да сәлам бирә. «Син кешеме?» – ди. «Юк, мин – маймыл», – ди тегесе. «Син кешегә охшаганмы?» – ди арыслан баласы. «Әле ничек кенә! – ди маймыл, горурланып, кукрәген кагып. – Бик күп ахмаклар мине үзләренең бабалары дип саный, мәктәпләрдә дә шулай өйрәтәләр…»

Арыслан баласының исе китә. Шулай исенә килә алмый йөргәндә, кеше куйган капкынга эләгеп һәлак була.

Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә («Тиен» сүрәсе, 4 аять): «Без адәм баласын күркәм сурәттә халык кылдык», – ди. Кызганыч, без еш кына кешелек сыйфатларыбызны югалтабыз шул.

Йәгез, бер дога!

ЗИРАТКА КЕРГӘНДӘ УКЫЛА

«Әссәләмүгаләйкүм әһләддийәәри мин әл-мүъминиинә үәл-мүслимиин. Үә иннәә иң шәәәәллааһу би-күм ләә-хикуунә әсъәлүллааһә ләнәә үә ләкүмүл гәәфийәһ».

МӘГЪНӘСЕ: «Аллаһның имиплеге булсын сезгә – кабердә ятучы мөэмин әһелләренә. Әлбәттә, Аллаһ теләсә, без дә сезгә кушылырбыз. Аллаһ бездән алда китүчеләрне дә, якты дөньяда калучыларны да гафу итсен, үзебезне дә, сезне дә җәфалардан коткарын сорыйбыз».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Мин = милләт

Асыл

КАМОЛИДДИН БОБОХОНОВ, ҮЗБӘК, 26 ЯШЬ

2015 елда Россиягә укырга дип килдем. Ул чакта мине алда нәрсә көтәсен әле белеп тә бетермәгәнмен. Ул чагында яшьтәшләрдән әллә ни аерылырга да теләмәдем. Әмма барыбер алар өчен «ҮЗБӘК» булыр идем. **ШУҢА ДА БУ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕМНЕҢ УҢАЙ ЯКЛАРЫН, ГҮЗӘЛ МӘДӘНИЯТЕБЕЗНЕ БУЛДЫРА АЛГАНЧА КУЛЛАНДЫМ.**

ҮЗБӘК СТИЛЕНДӘ КИЕМ-САЛЫМ КИЯ БАШЛАДЫМ, ТӨРЛЕ ДЕТАЛЬЛӘР КУЛЛАНДЫМ. Әти-әнидән махсус милли бизәкләр төшерелгән савыт-саба – чәйнек, тәлинкә, пиала алып килүләрен сорадым. Дуслар белән утырып чәй эчәр өчен монысы. **МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКНЕ КҮРСӘТҮНЕҢ БИК МӨҺИМ ҺӘМ БИК ЯХШЫ ИКӘНЕН АҢЛАДЫМ.**

МИНЕМ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕМ МИЛЛИ КУХНЯНЫ ҮЗ ИТҮЕМДӘ, ҮЗБӘКЧӘ ФИКЕР ЙӨРТҮЕМДӘ ДӘ ЧАГЫЛА. ШУЛАЙ УК ОЛЫЛАРГА МӨНӘСӘБӘТТӘ ДӘ КҮРЕНӘ БУ.

ТАТАРСТАНДА ҺӘМ, ГОМУМӘН, РОССИЯДӘ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ МИЛЛӘТ КЕШЕСЕ ҮЗЕН ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ЮНӘЛЕШТӘ КҮРСӘТӘ АЛА.

Мине башка милләттән булган яшьтәшләрем дә гел **ИЛҺАМЛАНДЫРА.** Шуңа сөенәм.

Һәр тел **МИЛЛИ КОДНЫ** саклый. Телне өйрәнеп, халык турында күбрәк белергә була.

Үзбәкләр – борынгы һәм мәдәни яктан бай халык. Безнең тамырларыбыз бик тирән. Мин үз Ватаным, илем, халкым белән горурланам. Бөтен дөньяда мәдәниятебезне күрсәтү һәм үзбәкләрнең җәмгыятьтә дөрес кабул ителмәвенә бәйле стереотипларны бозуны мөһим дип саныйм.

Камолиддин «Татарстан – мөмкинлекләр территориясе» коммерцияле булмаган автономиясендә эшли, Татарстандагы үзбәкләрнең милли мәдәни автономиясенең яшьләр бүлеген җитәкли. 2020 елда республиканың «Ел студенты» премиясен яулады.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

24 май | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БОМБА». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
15.45 «Татар сүзе» 6+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Каравай». Этномириада – 2023 6+
00.25 «Соотечественники». Альбина Шагимуратова. Примадонна Востока и Запада 16+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «Вечерняя игра» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
– Татарстан матбугатын җитәкчелек югарылыгында карасак – «Татмедиа» агентлыгы булсынмы ул, баш мөхәррир көнәфиләреме – бу урыннарны нигездә ир-атлар били. Ә кара эшне башкаручылар – көне-төне чабып, халык белән аралашучылар, мәгълүмат туплаучылар, материал язучылар – хатын-кызлар, – ди Линар. – Дөрес, хатын-кызлар эшләгән матбугатта социаль тармак, язмышлар, шоу-бизнеска аеруча күп игътибар бирелә. Әмма барлык мәгълүмат чаралары да «Сөембикә» журналыдай тоташ нәзакәтле булып бетә алмый шул. Тулы канлы, җитди, кискен сорауларны басмаларда хатын-кызлар белән ир-атлар арасында урталык – баланс булырга тиеш. Ир-ат булган җирдә сәясәт, икътисад, төзелеш, автомобиль хуҗалыгы кебек темалар да пәйда була. Безнең ил халкы яратып ашаган «Оливье» салатын бермәл бәрәңгедән яисә «Подшуба» салатын чөгендердән генә әзерләсәң, ни була? Матбугат чарасын да төрле ингредиентлардан торган тәмле бер әйбер буларак күзаллыйм мин.

«Татар укучысына җитди темалар кирәкми», – дип кырт кисүчеләр турында болай ди Линар:

– Биреп карамый гына алучының булу-булмавын аңламассың. Җитди материал язар өчен күп укырга, белергә, күп нәрсәгә төшенергә, үзең аша гаҗәп күп мәгълүмат үткәрергә туры килә. Әгәр туплаган белемең, тәҗрибәң, көне-төне чабып йөргән матди яктан тиешле дәрәҗәдә бәяләнмәсә?.. Кызганыч, Татарстан журналистларының хезмәт хакы мактанырлык түгел. Шуңа да бу өлкәдә уңышка ирешкән, әмма «яктырак кояш» табып, профессиядән китәргә мәҗбүр булган каләм әһелләре шактый.

Үзенең дә күзәткәне бар: төбәк журналистикасында хатын-кызлар күбрәк көч куйса, федераль басмаларда, телеканалларда шактый өлешне ир-атлар алып тора. Моны Мәскәүдә журналистларга матди мөмкинлекнең күбрәк булуы белән аңлатырга була, ди әңгәмәдәшебез.

– «Төбәкләрдә генә түгел, Мәскәүдә дә ир-ат журналистларга сорау зур», – дип гаҗәпләндергән иде күптән түгел Мәскәү телеканалларының берсендә эшләүче танышым, – ди Линар Закиров.

Кичәге журналист кызыксынып күзәткән гүзәл затлар кавеменнән булган каләм ияләрен дә атады.

– НТВ каналында эшләүче журналист Ирада Зейналованың осталыгына мөкиббән мин. Кирәк нәрсәне турыга бәреп әйтә, кирәк урында эзоп телен кучә ул... Эфирны алып барганда, менә-менә телевизор экраныннан бәреп чыгар сыман тоела. Татар ханымнарыннан Нәҗибә Сафинаның язмалары зур кызыксыну уята миндә. Шактый каршылыклы шәхес булса да, Нәҗибә апаның матбугатта басылып чыккан күпчелек фикерләре белән килешми булмый. «Татарстан яшьләре» газетасы нигездә укучы хатларыннан тора. Кайбер авторларның язу осталыгы профессиональ журналистныкыннан ким түгел. Шулар арасыннан Мамадыштан Миләүшә Хәйруллинаны билгеләп үтәргә кирәктер. Фикерен кистереп, дәлилләп, үтемле итеп яза ул, – диде Линар.

«Һәр редакциядә, бер булса да, ир-ат бар»

Шәм яндырып эзләсәң дә, матбугатта күренгән егетләр кытлыгын язучы, «Акчарлак» газетасы баш мөхәррире Алмаз Гыймадиев та сизә. 10 еллар элек вакыт кадерен белгән, эшкә йөри торган, төпле ир-егетләрне очратып була иде әле, ди ул.

– Татар дөньясындагы өч төп тармак: әдәбият, журналистика һәм мәгариф системасы хатын-кызлар кулына калып бара. Сәбәбе бик гади: бу өлкәләрдә хезмәт хакы түбән. Хәзрәтләр даими рәвештә әйтеп тора бит: ир-ат гаиләсен алып барырга, хатынын, балаларын тәэмин итәргә тиеш. Хатын-кыз эшләп тапкан акча – бары тик хатын-кызга, дип искә төшереп торалар. Алар белән килешмичә булмый. Ир-егетләр акчалы, авыр хезмәттә, фронтта, – диде Алмаз Гыймадиев.

Элегрәк елларда матбугат битләрендә «Баш редактор сүзе» дигән сәхифә булганын искә төшерде әңгәмәдәшебез. Ул чакта мөхәррирләрнең башлыча ир-ат булуын телгә алды. «Матбугат чарасы җитәкчесе дөньяга карашын, үз позициясен белдерә иде. Бу нәрсә юкка чыкты. Матбугатта ир-ат сүзе җитми. Позицияне белдерү бетте хәзер», – диде ул.

Әлбәттә, хатын-кызларсыз журналистиканы күз алдына да китереп булмый. Алмаз Гыймадиев әйтүенчә, алар бу тармакка нәфислек өсти. «Гүзәл затлар алып бара торган рубрикалар да шундый гына булсын иде. Судлар, низаглар – ир-атлар эше. Бу өлкәләрне яктырту гүзәл затларның матур сыйфатларын юк итә», – ди әңгәмәдәшебез.

Журналист кына түгел, матбугатны укучы да – хатын-кызлар бит. Алмаз Гыймадиев әйтүенчә, алар газетада сораштыру уздырып, басма мәгълүмат чарасын башлыча гүзәл затлар укуын ачыклаганнар. «Безне нигездә 35 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар укый. Ирләргә, димәк, матбугат белән танышу, гомумән, кирәкми?!» – диде журналист.

Әмма, әңгәмәдәшебез әйтүенчә, һәр редакциядә үз эшенә фанатларча бирелгән, бер булса да, ир-ат бар. «Йә шагыйрь, йә язучы, йә журналист ул», – ди Алмаз Гыймадиев.

«Әлегә акча җитә»

«Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалында корреспондент булып эшләүче Рүзәл Шәрипов – татар журналистикасындагы сәләтле һәм сирәк егетләрнең берсе. Әлегә – студент. Моңа кадәр «Татарстан» радиосында хәбәрче булган, яшьләр өчен саналган матбугат чараларында да каләм чарлаган егет.

– Журналистикада хатын-кызлар күп, әмма ул алар кулында гына дигән сүз түгел. Ир-атлар бар, аларның фикерләре үтемлерәк, аларга башкача карашы, бу сер түгел, – ди Рүзәл. – Журналларны да күбрәк гүзәл затлар укый, радионы да алар тыңлый, телевизорны да алар карый. Шуңа да аларга ир-ат фикерен ишетү, күрү, уку кызыграк.

Ир-егетләр журналистикага хезмәте күп, акчасы аз булганга күрә килми дип тә әйттек инде. Рүзәл бу хакта менә нинди фикердә:

– Ир-атларга акча күбрәк кирәк. Алар гаиләне тәэмин итәргә тиеш. Әлегә мин – студент. Эшләгән акчам үземә җитә. Әмма, гаилә кору мәсьәләсе килеп баскач, бу акча җитмәячәк. Начар хезмәт хакы алам, димим. Әмма минем ихтыяҗларым белән...

РОССИЯДӘ ЖУРНАЛИСТИКА ТАРМАГЫНДА ХЕЗМӘТ ХАКЫ

- **44**% >> **60 мең сумнан азрак**
- **20,1**% >> **61–80 мең сум**
- **14,1**% >> **81–100 мең сум**
- **13,6**% >> **101–150 мең сум**
- **5,4**% >> **151–200 мең сум**
- **2,7**% >> **200 мең сумнан күбрәк**

Pressfeed сораштыруы нәтиҗәләренә нигезләнеп

Фикер

Рәмис ЛАТЫЙПОВ,
«Татар-информ» агентлыгының татар редакциясе баш мөхәррире:

– Берәр юнәлештә хәлләр мөшкелләгән каян белеп була? Хатыннар килүеннән. Дилбегә хатын-кыз кулына күчә, тәртәгә хатыннар җигелә икән, көт тә тор – димәк, бу әйбер бетте дигән сүз. Эшләр күкрәп барсын өчен, аны ирләрнең җигелеп тартуы кирәк. <...> Менә хәзер бит инде шигърият хатын-кыз кулына калды, дибез. Дөрестән дә шулай бит. Ә бит татар шигъриятендә дә гомер бакый ирләр булган. Ә хәзер – хатын-кызлар. Прозада алай ук түгел әле, ирләр бар. Димәк, проза бетми бугай әле. Язучылар берлеге белән дә мөшкел түгел хәлләр. Журналистикада да шулай. Менә элекке фотоларны карыйсың – элекке редакцияләр! Анда бит ирләр! Телевидениедә гомумән журналистлар ирләр командасы булган заманнар бар иде. Хәзер алай түгел. Башкача. Әмма әле баш мөхәррир итеп куярлык ир-егетләр бар. Димәк, алай ук эшләр мөшкел түгел. «Кара, хатын-кыз килә икән, башын бетерергә килә, хатын-кызларны юкка чыгаручы дип атый», – дип аңлап, мине сексист, юньсез дип сүгәргә ашыкмагыз. Киресенчә. Хәлләр аяныч, бөтен нәрсә җимерелеп беткәндә, кулына эш алырдай ирләр калмаганда, хатын-кызлар чарасызлыктан бу өлкәгә килә һәм авырлыкны үз җилкәсенә сала. Алар, әни буларак, бу өлкәне яшәртмәкче була, ана инстинкты уяна аларда, алар бу өлкәнең үлүен күтәрә алмый, ирләрдән булмаганга үзләре тотына. Алардан да булмый икән, димәк, бетә дигән сүз. Ягъни хатыннар килгәнгә бетми. Алар инде бетеп барганны коткарырга килә. Хатыннар килүе ул – соңгы шанс.

(Социаль челтәрдәге шәхси сәхифәсеннән кыскартып бирелде.)

ФИДАН МӨХӘММӘТОВ:

«ЯТИМНӘР ЙОРТЫНА ҮЗЕМ БАРДЫМ»

Сынаулар көчле кешегә бирелә. Күтәрә алмаслык хәсрәт юк. Бары тик үзеңне кулга алу гына кирәк! Чаллыда яшәүче 35 яшьлек Фидан Мөхәммәтов әнә шулай дип яши. Бер уйласаң, әле яши генә башлаган дияргә дә була үзен. Әмма шушы гомерендә күрмәгәне калмаган аның.

Йөрәк яраларын онытырга тырыша ул. Башкаларга да шуны өйрәтә. Ун елдан артык фитнес-тренер булып эшли, физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә тернәкләндерү күнегүләре өйрәтә, шушы юнәлештә студентларга да белем бирә. Буш вакытларында «Мин ятим түгел» дигән марафон оештырып, ерак арага йөгерә. Башкаларны да үзенә ияртә. Фидан – Эльбрус тавына да менгән кеше.

– Мин бар эшемне башкаларга үрнәк булыр өчен эшлим. Кешеләр төшенкелеккә бирелеп, тормышларын җимереп яшәргә тиеш түгел. Көчле булырга кирәк, – ди Фидан. – Тормыштаниләр генә күрергә туры килмәде. Нинди мул ризыклы заманда ачка да тилмердем, явызлык, усаллык белән очраштым, якыннарымны да югалттым. Балачагым бик авыр хатирәләр белән истә калды. Әтием эчәргә ярата иде. Миңа дүрт яшь чакта исереп кайтып, әниемне бик каты кыйнады. Әни энем белән мине күршеләргә кертеп куйган. Ә үзе өч көннән хастаханәдә үлде.

Әтиләрен кулга алалар. Ике ятим малайны әби белән бабайга тапшыралар. Тик бабасы да салырга хирыс була. Эчү юнълегә итми, ул бераздан авырып китә. Ә инде күп тә үтми, вафат була. Шуннан соң сабыйларны әтисе ягыннан туган апасы тәрбиягә ала. Малайлар Чаллыда яши башлый.

– Тугыз яшемдә әтигә төрмәгә хат язып салдым. Бөтен тормышыбызны сөйләдем. Хат озын иде. Тик бераздан бу хатны кире кайтардылар. Безне тәрбияләгән апам кайтты да, әтиегез үлгән, диде. Без тома ятим калдык. Сынау арты сынау килеп торды безгә. Кинәт кенә апамның ире үлеп китте. Бу вакытта миңа – 10, энемә 7 яшь иде. Безгә дә авыр булды. Инде аларга иялләшкән идек. Апамның улын армиягә алдылар. Апам бу хәсрәтне күтәрә алмады. Шешәгә үрелде, башка ирләр алып кайта башлады, – дип сөйли Фидан.

Инде нишләргә? Малайларга көн бетә. Фидан энесен ияртеп, опека бүлегенә килә.

– Килдем дә, зинһар, безне ятимнәр йортына урнаштырыгыз, дидем. Безнең өчен шаккатмалы тормыш башланды. Көнгә өч тапкыр ашаталар, киемнәр бирделәр.



Фидан Мөхәммәтовның шәхси архивыннан

Шуны күреп сөендем. Дәресләр әзерли башладым. Уку бушка китмәде, 9 нчы сыйныфны яхшы билгеләргә генә тәмамладым. Ниһаять, күңелгә тынычлык таптык, – ди Фидан. – Мин ятимнәр йортында эшләгән һәр кешегә рәхмәтлемен. Зарлана алмыйм. Тәрбиягә, җылы сүзгә сусаган булганбыздыр инде без. Тик күңелдә ятимнәр йортында үскәннең тамгасы кала аның. Әти-әнисез үскән баланы әллә каян танып була. Алар башкалар алдында кимсенеп яши. Аннары, ятимнәр йортыннан чыкканнарга башка караш та бит әле. Берәү дә бер җирдә дә колач җәеп каршы алып тормый. Бик күпләр тормышта үз урынын таба алмыйча харап була. Кешеләргә ачулы булалар, усалланалар, эчүгә сабышалар. Үз юлыңны табу кирәк. Нинди генә хәлдә калсаң да, үз язмышыңны дөрес кабул итәргә һәм тормышка карашыңны үзгәртергә кирәк.

Ятимнәр йортыннан чыккач, Фидан ветеринария училищесына укырга керә. Маллар яратуы бабасыннан күчкән аңа. Укып бетерүен бетерә, әмма башка юл сайлый. Идел буе дәүләт физкультура, спорт һәм туризм академиясенә укырга юл тота. Менә шунда үзенең кешеләргә ышануы аркасында акчасыз кала. Ике атна буе юньләп ашарына булмый. Урларга өйрәнә. Тамак хакы үзенекен итә шул... Ул үзенең мөстәкыйль тормыш итә белмәвен аңлый. Ятимнәр йортында моңа өйрәтмиләр икән! Аның каравы тормыш өйрәтә аны. Һәр очрак сабак була үзенә. Тезләнеп елаган чаклары да күп була.

– Тулай торакта яшәгәндә олырак малайлар телефонны урлады. Соңрак аларның наркоман икәнен белдем. Шунда бер егет Аллаһы Тәгалә турында сөйләде. Ышану ярдәм итә, диде. Миндә Раббымнан ялварып ярдәм сорадым. Ышанасызмы, күп тә үтмәде, миңа бер яхшы күңелле кеше акча бирде. Мин догаларның һәм теләкнең кабул булуына ышандым. Күңел чистарды. Әкренләп бар кешене кичерә алдым, – ди ул. – Үкенечләр дә юк түгел. Әтиемне күреп булмады. Апама рәхмәтемне әйтә алмадым. Ул да исән түгел инде. Әмма яшәргә кирәк. Тормыш дәвам итә. Бар да үзеңнән тора. Тормышым моңа бер мисал. 21 яшемдә үз теләгем белән гаилә кордым. Стипендия акчасына йөзек сатып алдым да булачак хатыныма тәкъдим ясадым. Ул ризалашты. Ә миндә үземә ышаныч артты. Яшәп киттек. Балабыз үсә. Үткәннәрем артта калды инде. Бүгенге белән яшәргә яратам.

Фидан – ятимнәр йортында да еш кунак. Ярдәм итәргә дә тырыша, анда тәрбияләнүчеләр белән сөйләшә. Тормышның матур якларын күрсәтергә омтыла. Аларның кимсенеп яшәмәүләрен тели ул.

– Мине ятимнәрне тәрбиягә алып, кире кайтару очраклары борчый. Бер егет белән дуслаштым. Аны биш тапкыр кире кайтарганнар. Болай эшләргә ярамый бит. Рухын сындырмасак иде сабыйларның, – ди Фидан. – Ятимнәрне ярата алсагыз гына якын итегез! Мин гомерем буе үзебезне сыендырган балалар йортына рәхмәтлемен. Анда эшләүчеләрнең яратуы яшәргә көч бирде дә инде!

Үз гомеремдә дүртенче тапкыр хастаханәгә эләктем... Иртәнге якта кабул итү бүлегендә утыра идем инде. Бераздан 12 нче палатага озатып та куйдылар. Тәүлек буе ятучы ике хатын-кыз янында мин өченчесе булдым.

vk.com

УНИКЕНЧЕ ПАЛАТА

Тәрәзә янындагы Мөршидә апага 75 яшь, Казан карчыгы икән. Хәер, аны әле әби дип әйтеп булмый. Төз гәүдәле, йөгереп йөри. Укол һәм система алып кайтып китәсемне белгәч, сүгеп үк ташлады:

– Булнистә яту дип аталамы инде бу? Үзеңне карарга кирәк. Авыру хатын берәүгә дә кирәкми. Авырсаң, балалар да яратмый. Гомерем буе вакытында дәваландым. Тормыш куган буласыз, кайсыгыз тоткан соң аны?!

Икенче караваттагысы – рус милләтеннән. Борчылудан авырый башлаган. Табиблар диагноз куя алмый интегә икән. Көчле дарулар белән генә яшим, ди.

– Ирем хыянәт итте. Шуны белгәч, томан эчендәге кебек яшим. Шундый сәер хисләр. Психотерапевтта булдым, башым дөрес минем. Әле бит 50 яшь тә юк. Кече кызым техникумда укый, олысы кияүдә инде. Өч ай эшлим дә бер ай дәваланам. Күренмәгән табиб калмады, нинди генә профессорлар карамады. Төгәл диагнозны әйтүче юк. Әмма гомерлек чир икәнен яшермиләр. Шуңа күрә бүген белән яшим, – ди ул.

Бик ярдәмчел үзе. Хастаханәдәге тәртипләрне аңлатып бирде. Кайчан карама, уйга баткан. Ирен сагынып яши икән.

Өченче көнне палатага Настяны керттеләр. Ут хатын! Тавышы көчле, бөтен кеше белән дә уртак телне тиз тапты. Казанныкы, моңарчы башка хастаханәдә яткан. Белмәгән табибы юк. Моннан 10 ел элек, 43 яшендә авырый башлаган.

– Биш ел инде эшли дә алмыйм, инвалидлык та бирмиләр. Миндәге авыру белән тиеш түгел, диләр. Ничек яшәргә соң? Ай саен кыймммәтле дарулар эчәм. 20–30 мең сум китәдер. Әле ярый ирем эшли. Заманында 4 катлы йорт төзегән идек. Ике малай үстереп, берсе дә безнең белән калмады. Авыргач, беренче каттан өскәрәк күтәрелгәнем юк. Быел сатарбыз, дибез. Безгә бер бүлмәле фатир да җитә, – ди ул.

Бүлмәгә бишенче апаны салдылар. Районнан килгән. Аягына баса алмый, көчкә йөри. Гаеп – умырткалыкта, дигәннәр. Гөлчәчәк – күпне күргән татар хатыны. 34 ел яшәгәннән соң, кул күтәрүенә чыдый алмагач, иреннән аерылган. Олы кызы килеп, әнисен алып киткән.

– Татар гаиләсендә үскән кеше бит мин. Авылдашыма кияүгә чыктым. Кая ул кире кайту! Безнең заманда түзәсе иде. Эчкәненә дә, сукканына да. Өйдә тыныч кына йоклаганымны хәтерләмим дә мин. Гомерем буе кешедә кундым. Өч бала таптым, аерылып китәрмен дип уйламадым да, – ди ул. – Дүртебезне дә кыйнады. Кызым белән кияү килеп алган көнне беренче мәртәбә изрәп йоклаганмын. Иртән кызым янымa керде дә: «Әни, йоклый алдыңмы? Кияүгә чыкканнан бирле, төннәр буе синең исәнлегеңне теләп яттым», – ди. Кыйнаса да, үзләрен какса да, балалар әтиләрен дошман күреп үсмәде. Холкы шундый, үпкәләмәгез, дип өйрәттем. Күпме генә ялынса да, кире кайтмадым, ул да өйләнмәде.

Гөлчәчәк апаның сызланмаган җире юк. Умыртка баганасына зыян килгән. Мин чыгып киткәндә, аягына басты ул. Әкренләп йөри башлады.

– Гомер тиз узды. Үзем өчен яшәмәдем дә инде мин. Үткәннәрне искә төшерсәм, үкереп елыйсы килә. Никләр балам белән чыгып китмәгәнмен, дип үкенгән чакларым күп булды, – ди ул. – Кыйнауга, рәнҗетүгә түзеп яшәмә икән. Мин дә бит берәүләрнең газиз баласы идем. Үз улларым кул күтәрү түгел, хатыннарына авыр сүз дә әйтмиләр. Күреп үсте алар. Гаиләне саклыйм дип, үзеңне сакламыйча яшәргә ярамый икән! Соң аңладым, әмма шуңа да сөенәм әле.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РУШАН ШӘМСЕТДИНОВ:

«РӘССАМ РУХИ ЯКТАН ГЫНА БАЙ, МАТДИ ЯКТАН ТҮГЕЛ»


Илдар Мөхәммәтҗанов

Сафьян урамыннан Каюм Насыйри урамына аяк басканда, ике катлы агач йортка тап буласың. Аның тирәсендә башка агач йортлар калмаган инде. Бу – танылган рәссам Рушан ШӘМСЕТДИНОВ яшәгән һәм иҗат иткән йорт. Без аның белән татар тарихына танылган шәхесләрен биргән әлеге нәсел, Иске Татар бистәсе тарихы һәм рәсем сәнгате проблемалары хакында сөйләштек.

:: Рушан абый, Исәнбаевлар йорты бүген нинди хәлдә?

– Дәү әти бу йортны 1928 елда сатып алган. Дәү әтиләр бирегә хәзерге Серов, элеккеге Надеждинск шәһәреннән күченеп кайтырга мәҗбүр булалар. Башта совет власте безнең гаиләгә тимәсә дә, утызынчы елларда, коллективлаштыру шаукымы башлангач, безне дә кыса башлаганнар. Шуңа күрә аларга Надеждинск шәһәрендәге 48 тәрәзәле йортны һәм зур гына җир участогын сатарга туры килә. Соңыннан ул йортта Надеждинск шәһәре хакимияте урнаша. Надеждинск – металлургия шәһәре. Дәү әтием Гайнетдин белән дәү әнием Бәдриҗамал әлеге калага яңа тормыш башларга дип киткәннәр. Алар икесе дә – Апас ягы крестьяннары. Бабай заводта эшче була, завод өчен атлар үрчетү белән дә шөгыльләнә. Чөнки авыр йөкләрне ташырга ни автомобиль, ни трактор булмый, атларның бик кирәк чагы. Әби өйдә бала тәрбияли. Ун баладан алтысы исән кала. Бусы – патша вакытындагы хәлләр. Аннары совет власте килә. Дәү әти яңа властька да завод өчен атлар үрчетүен дәвам иттерә. Аннары аларның иркен яшәүләре кемнәргәдер ошамый башлый. Нәтиҗәдә гаилә Казанга кайтырга була. Күп кенә йортлар арасыннан Апанаевлар мәчете мәзине Мостафа Исәнбаев йортын сайлап алалар. Бу йорт 1880 елда ук салынган. 1889 елда атасы аны улы Ибраһимга бирә. Совет заманында исә бу йортта барлыгы 12 гаилә яшәде. Хәтта ишегалдындагы мунчага да бер гаиләне керттеләр… 2012–2013 елларда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә реставрация эшләре үткәрелде. Мин шушы йортта тудым, шушында үстем, хәзер дә биредә яшим, эшлим. Безгә бигрәк тә җәй айларында күп кенә туристлар килә, барысын да кабул итәбез, чәйләр эчерәбез. Менә хәзер әле ремонт эшләре белән шөгыльләнәбез.

:: Иске Татар бистәсен торгызганда куелган бурычлар үтәлдеме?

– Бистәне торгызу эшләре башланганда, кызганыч, күп кенә йортлар сүтелеп өлгергән иде инде. Тузган торак программасы бер яктан яхшы булса, икенче яктан әнә шундый зыяны тиде.

> Иске Татар бистәсе Иван Грозный Казанны яулап алгач барлыкка килә. Үзәктән татарлар бирегә чыгарыла. Нәтиҗәдә Кабан күленең бу ягы мөселман ягы булып оеша. Монда сәүдәгәрләрнең, морзаларның, хәлле кешеләрнең берсен-нән-берсе матур йортлары, мәчетләр, мәдрәсәләр, җыен мәйданнары корыла. Һөнәрчелек гөрли, сәүдәгәрлек җайга салына. Ни кызганыч, хәзер инде шул йортларның ун проценты гына сакланып калды. Бурычлар 10 процентка үтәлде, дияргә буладыр.

:: Шәмсетдиновлар нәселеннән күп кенә атаклы кешеләр чыккан. Каюм Насыйри белән туганлык кайсы яктан?

– Әни ягыннан Сәгыйтовлар нәселе Каюм Насыйрига барып тоташа. Ул да – борынгы нәсел. Сәгыйт Морза дигән полководец булган. XV гасыр тарихын өйрәнгән тарихчылар аның шәхесен яхшы белә. Ул бөтен сугышларда да җиңгән, дип әйтәләр. Шушы нәсел җебен алсак, 14 буын алмашынганнан соң, мин туганмын инде. Бабамның бабасы Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов белән Каюм Насыйри туганнан туган абыйлар була. Мөхәммәтйосыф бабай тарихка Бишенче җәмигъ мәчетнең соңгы мулласы булып кереп кала. Күрәсең, эшен бик әйбәт белгәндер, аңа патша алтын медаль тапшыра. Шул медаль белән фотосы гаилә архивында саклана. Аңа ярдәмче итеп Галимҗан Баруди сайлангач, бабай эше тәнкыйтьләнә башлый. Ул чакта сиксәнне узган карт үзгәрә алмагандыр инде, ә Баруди – җәдитче. Бабайлар шушы мәчет каршындагы ике катлы агач йортта яшәгән. Ул йорт хәзер юк инде.

:: Каюм Насыйрига бәйле ядкәрләр сакланамы сездә?

– Кызганыч, юк шул. Аның фотосы да сакланмаган бит. Бездә әнисе Әминәнең фотосы да юк. Аннан соң динле кешеләр фотога бик төшмәгәннәр дә инде. Ә бөтен дөньяга таралган портретын рәссам Байназар Әлминов кеше сүзенә таянып кына ясаган. Иң кызыгы: Каюм Насыйри сурәте белән Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов фотосын чагыштырсак, алар ике тамчы су кебек охшаш.

:: Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романында Каюм Насыйри образы да бар. Ул анда ярым сукыр, авыр хәлдә яшәүче галим буларак сурәтләнә. Бу дөреслеккә туры киләме, сезнеңчә?

– Мөгаен, шулайдыр. Аның үз йорты да булмаган бит, кешедә торган. Әнә шул йорт нигезендә хәзер Насыйри музее эшли.

:: Сез – тарихи темага алынган беренче рәссамнардан. Бүген инде бик күпләр әлеге темага алына. Әмма тарихи дөреслек ни дәрәҗәдә сакланган?

– Казан сәнгать училищесын тәмамлаганда, диплом эшемне Казан ханлыгы тарихына багышлыйсым килгән иде. Бу – 1966 ел, училище җитәкчесе – партия кешесе, заманча тема алырга киңәш итте. Янәсе, тарих үткәндә калырга тиеш. Шуңа күрә җәлилчеләр темасын алдым. Әмма ул вакытта ниятләгән теманы – Сөембикәнең Сафагәрәй белән хушлашуын барыбер эшләдем. Ул «Мирас» журналында басылып чыкты. Аңа кадәр китап нәшриятында, «Социалистик Татарстан» газетасында да эшләп алдым. Бик кызык чор иде ул. Әнәс Әмирханов белән бергә эшләдек. Рәсем дә ясадым, портретлар да, фотоларга ретушь та эшләдем. Ул чакта шрифтлар да кулдан языла иде бит. 1975 елда Мәскәү полиграфия институтына укырга кердем. Анда да дипломны тарихи темага яздым. Дөрес, Мәскәүгә безнең тарих кирәкмәде, 1981 ел бит. Ленин темасына триптих ясадым. Ул хәзер Ленин музеенда сакланырга тиеш. Тарихи портретларга мин «Мирас» журналында эшләгәндә алындым. Иң элек Алтын Урда ханнарын эшләдем. Башта тарихи материалларны өйрәндем. Шуннан китте инде, Болгар чоры, Казан ханнары…

:: Милләтчелектә гаепләмәделәрме?

– Берзаман «Вечерняя Казань» газетасында, милләтчелектә гаепләп, материал чыкты. Автор, мөгаен, татарны надан, үткәне булмаган халык итеп күрергә теләгәндер. Ник дигәндә, ханнар портретлары матбугатта басыла башлагач, халыкта кызыксыну артты. Бик күп кеше журналга язылды. Без инкыйлабка кадәр дә безнең бик бай тарих булуын чагылдыра алдык дип уйлыйм мин. Рәссамнар да тарихка тартыла башлады. Китап нәшриятында эшләгәч, материал кул астында. Үзем генә эшләмәдем, башкаларны да чакырдым. Хәзер дә ясыйлар, әмма бик азлар гына бу юнәлештә калды.

:: Иске Татар бистәсендә сезнең өчен иң кадерле урын кайсы?

– Үзем торган йорт, балачагым үткән урыннар. Апанай мәчетендә элек ясле

иде. Бер яшемнән биргәннәр. Аннан шундагы балалар бакчасына 7 ел йөрдем. Мин укыган мәктәп бинасы патша заманында Касыймия мәдрәсәсе бинасы булган. Без аны «кәҗә мәктәбе» дип йөртә идек. Бистәдә кәҗә белән сарыкларны күп асрыйлар иде, сыер сирәгрәк. Көтү кайтканда, кәҗәләрне шунда куып керткәннәр. Мин укыганда, ул рус мәктәбе иде инде.

:: Рус мәктәбен тәмамлаган кешеләр, гадәттә, татарча белми...

– Безнең өйдә русча сөйләшүче юк иде бит. Русчаны яхшы белмәгәнгә, безне рус мәктәбендә укыттылар. Әмма беребез дә татар телен онытмадык. Улларым да татарча яхшы белә.

:: Музыкага һәвәслегегез кайдан килә?

– Ул сәләт, мөгаен, дәү әни Бәдриҗамалдан килә торгандыр. Ул скрипкада, кубызда, гармунда уйнарга үзлегеннән өйрәнгән. Профессиональ музыкаль белемне әтинең энесе Исмай Шәмсетдинов кына алган. Ул – композитор, артист. Әмма гаиләдә әти дә, абый да фортепианода, думбрада, Амати технологиясе буенча ясалган скрипкада уйный белгәннәр. Страдивари скрипкалары иң әйбәтләре, икенче урында Амати килә. Әлеге скрипкалар XIX гасырда ясалган, яңгырашы искитмәле. Мин аларны саклап тотам инде.

:: Уйный беләсезме?

– Музыка мәктәбендә скрипка классын тәмамладым. Ул миңа иҗатта ярдәм итә. Күп рәссамнар скрипкачыларны дөрес ясамый. Скрипканың грифы кулда ятарга тиеш түгел, ул һавада булырга тиеш.

:: Бүген рәссам ничек яши?

– Рәссамнарның хәле яхшы түгел. Рәсем хәзер беркемгә дә кирәкми. Заманча техника рәссамнарның кадерен юкка чыгарды, дип әйтсәк тә була. Китапка иллюстрацияләр ясау гына калды.

:: Рәссам булырга хыялланган кешеләргә киңәшегез бармы?

– Үзем укыган сәнгать училищесын гына алыйк. Анда хәзер кызлар гына укый. Элек киресенчә иде. Элегрәк Казанда Сәнгать институты бар иде, ул да ябылды. Бу да бит инде рәссамга ихтыяҗ булмаганнан килә. Гомумән гуманитар юнәлешне алсак та, ул тармакларда хәзер хатын-кыз. Аларга әле иҗат кирәк, әмма иҗат белән бүген тормышны алып барып булмый. Рәссам булып байыйм дип хаталанмасыннар.

:: Шул ук вакытта иркен яшәүче «модный» рәссамнар да бар бит.

– Аларның күбесе безнең милләт кешеләре түгел. Яһүдләр, мәсәлән, сәнгать тармагында уңышлы иҗат итә. Никас Сафронов иҗатын алсак, аның мәктәбе көчле. Реализм мәктәбен әйтүем. Ул үзе: «Мин «обыватель» күңеленә юл таптым», – дип әйтә.

:: Ә төрле алымнарны кулланучылар, әйтик, буяу чәчрәтеп ясаучылар турында ни әйтерсез?

– 2–3 рәсем ясыйсың да, туйдыра ул. Үсәр өчен, техниканы алмаштырырга кирәк. Сүз уңаеннан, абстракт рәсемнәр дә модадан чыкты. Ул СССР заманында хәтта тыелган иде. Реклама, шул картиналарны аһ итеп мактау үз эшен эшли, сәнгать кыйммәте булмаган әйберләр миллион сумнарга сатыла. Менә бит халыкны ничек бозалар. Болар барысы да белем булмаганнан килә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

ОЛАБЫЙ

(хикәя)

Җил ниндидер бер ашыгычлык белән салкын тәрәзәгә килеп бәрелде. Аңа ияреп килгән эремчек кебек шадра кар бөртекләре шыбыр-шыбыр тәрәзә төбенә коелды да, җил аларны җыеп, янә очыртып алып китте. Агач өй бүрәнәләрен сыйпагандай шыбырдап куйды. Нык иде әле бүрәнәләре.

Шуңа да өй эчендә дә җылы. Мичтә биешкән ялкын телләре дә, чытыр-чытыр килеп янган коры утын да, мич алдына төшкән яктылык та тәнгә генә түгел, җанга бер рәхәтлек биреп тора.

– Сёмага дигән кыстыбыйларны ныграк майла, аңа тагын берне өстәсәң дә ярый. – Муса агай хатынына шулай диядия, шкафтан муенлы свитерын алып киде. Үзе йомшак, үзе җылы шушы свитерны шактый еллар элек хатыны Җиһан бәйләгән иде. Яшьрәк чагында ук. Бәйләргә өйрәнәсе килә дип, әллә каян гына юнәтеп, өч төсле җеп алып кайтты да бәйләм инәләренә күз җыярга өйрәнүгә шушы свитерга тотынды. Гади булса да, үзенчә матур килеп чыкты. Һәрхәлдә, хәләле сүз белән үтереп мактамаса да, бер кадерле әйбере итеп саклап тота. Көзгә кергәч алып кия, яз җиткәч, янә хатынына салып бирә. Җиһан апа аны куе исле сабынны җебетеп, йомшак җылымса суда юып киптерә дә киләсе елга кадәр дип төреп алып куя. Елдан-ел шулай: свитер искерми дә, тузмый да, җылысын да югалтмый.

– Сёмага дигәнен дә, синә дигәнен дә майлыйм. Үзең турында уйла син, төне буе керфек тә какмый, каравылда сиңа торасы. Сёма ул, ичмасам, син алып килгән кыстыбыйларны ялт иттерер дә кикерә-кикерә, корсагын кашып яткач, гырлый-гырлый йокы симертер. – Җиһан апа иренең гадәтен белсә дә, уендагысын әйтми калмый. Хәер, Муса агай өч көнгә бер каравылга киткән саен шул сүзләрне кабатлый, әмма ире кушканны җиген җиккә китереп эшләп куя. Эшләми кая барсын, Мусасы барыбер үз дигәнен итә инде аның.

– Ноябрьгә кергәндә, безнеке кебек шартларда яшәүче кешеләрнең каны, кыш киләсен сизеп, салкынга әзерләнә башлый. Кан йөреше әкренәя, йокы баса, күбрәк майлы ризык ашыйсы килә. Бу – безнең бик борынгы заманнарда яшәгән бабаларыбыздан ук килә торган гадәтләр. Без генә түгел, бөтен җан иясе кышка әзерләнә. Кайсыдыр кышка ризык җыя, оя кора, кайсыдыр мамык үстерә, туң алыштыра...

Муса агай сукбай Сёмага карата аеруча хәерхаһлы. Берәүдән дә, хәтта станция начальнигыннан да сүз әйттерми. Тегесенең станция тирәсендә еш йөрүен өнәми яңа начальник, шуңа да Муса агай аны алай итеп тә, болай итеп тә хәйләли, тәки йолып кала. Тел-теш тидертми, җил-яңгырдан саклый. Җил-яңгырдан дигәндә, туры мәгънәсендә саклый: үзенең сменасы туры килгән төннәрдә каравылчы булмәсендә кундырып чыгара, шунда ашата-эчертә. Әле шул рәвешле кайгыртуын ничектер башкалардан, хәтта Сёмадан да яшерергә теләгәндәй, үзеннән-үзе шулай килеп чыккандай итеп күрсәткән була. Менә бу юлы да «Сёмага күбрәк, майлырак ашарга кирәк» диясе урында карчыгының ике ятып, бер төшенә дә кермәгән фәлсәфәләр сөйләп ташлады.

– Аңа кыш ни дә, җәй ни. – Җиһан апа барыбер үзенекен кыстыра. Һәм шул сүзе белән йомшак тастымалга төреп, эшкә йөри торган биштәргә салган кайнар кыстыбыйларны иренә тоттыра.

– Ишекне үзем бикләп чыгармын, иртән эштән кайтуга синә уятып торасы булмас, – ди Муса агай, җавап итеп. – Кышка таба таң йокысы аеруча тәмле була ул...

***

Гадәттәгечә, сөйләшә-сөйләшә, дөресрәге, сукбайның соңгы ике-өч көн эчендә күргәннәрен тыңлый-тыңлый, әле суынырга өлгермәгән кыстыбыйларны ашап куйгач, станциянең һәркем тарафыннан диярлек сөекле мәчесе Мырауны да сыйлап, аның мыекларын пәхтәләп юганын сүзсез генә кинәнеп карап утыргач, һәм шушы ике мәхлук үзләрен дөньядагы иң бәхетле җан иясе икәнлекләренә инанып, тар сәкегә ятып, мес-мес килеп, йокыга талгач, Муса агай, төнге поездны каршы алып озатып калырга дип, перронга чыкты.

Кыш булып уйнарга яратучан ноябрь эремчек карын кая куярга белмәгәндәй, анда-монда сибереп йөртүеннән туктаган, төнен тагын да суытырга итеп, томан төшеп килә. Кайчандыр өяз шәһәре булганда, XIX гасырда ук салынган тимер юл станциясенең перроны да әллә ни үзгәрешләр кичермәгән иде. Патша заманыннан калган иске фонарьларының да сары уты томаннан качарга теләгәндәй тыгызланып, йомарлам гына булып калган. Алай да дөм караңгы түгел, шәүләләрне азмы-күпме аерырлык кына булып ай яктысы, тәрәзәләрдән электр уты төшеп тора. Әнә, рельслар телгә килеп, поездның якынлашуын хәбәр итте. Күп тә үтмәде, тәгәрмәчләрен газиз бер ритмга салып көйләтә-көйләтә, поезд күренде һәм рельсларны сызгырта-сызгырта үзе белән ниндидер бер тантаналы ыгы-зыгы алып килде. Ничек тиз башланса, станциядәге ыгы-зыгы шулай ук кинәт тынып калды. Ике-өч минут эчендә биредә каласы пассажирлары төшереп, яңаларын алды да тепловоз, томан эченә җылы төтенен өреп, вагоннарын сөйрәп китеп тә барды. Озакламый поезд тәмам күздән югалды, төтене таралып, тирә-як элеккечә бәләкәй шәһәрләрдә генә була торган салмак гүләү тавышына күмелде. Муса агай бусын да озаттым, бар да тәртиптә дип, тыныч күңел белән керү ягына таба борылганда, кырый күзе белән генә күреп алды да инде аны.

Дөресрәге, иң элек перрондагы соңгы фонарьның саран яктысында аның озын шәүләсе күзгә чалынды. Шәүлә селкенми иде, Муса агай да шып туктап калды һәм чекерәебрәк караса, аның кеше икәнен чамалап алды. Поездан төшүенә каршы алырга килүчесе соңгы калган, ахрысы, дип уйлады тимер юл станциясенә аша үтеп йөрүче пассажирларның холкын тәмам өйрәнеп бетергән Муса агай. Күрәсең, беренче килүе, кая барырга белми аптырап калгандыр дип, гадәтенчә, теге кеше янына ашыкты. Каршында озын какча буйлы, әллә картлыгыннан, әллә куркуыннан, әллә өшүеннән муенын алгарак сузып, иңнәрен җыерып, бөкрәеп басып торган, бәләкәй генә төенчеген ике куллап күкрәгенә кыскан, ничек кенә җылы итеп киенсәң дә, үзәкләргә үтә торган юеш салкын көнне юп-юка пәлтәдән, бары бер кат яулыктан, җыерчык баскан ак йөзенә караганда, 80 белән 90 яшь чамасындагы бер карчыкны күреп имәнеп китте. «Хода бәндәсе, нишләп йөрүең инде?» – дип куйды ул үз-үзенә, эшнең нидә икәнен чамалап, чөнки кемнеңдер кеме – берәүнең кадерлесе төн уртасында шушы яшьтә, мондый кыяфәттә юлга чыкмавын бер караштан аңларлык кына тормыш тәҗрибәсе Муса агайда тулып ашкан иде.

Ә Хода бәндәсенең каян килүе, кая юл тотуы, хәтта исемен дә тәгәл генә белмәве ачыклангач, Муса агайга карар кабул итәр өчен тирән итеп бер сулыш алырлык вакыт кирәк булды: иң элек әбине җылыга алып керергә, кайнар чәй эчерергә, иртәнгә кадәр ял иттерергә кирәк иде. Аннан соң күз күрер...

***

– Менә сиңа авырткан башка тимер таяк! Башка проблемаң юкмы әллә? Тот та полициягә тапшыр, алар аны кая куярга икәнлеген бик тиз хәл итә. Ә болай үзеңә мәшәкать кенә, – дип акыл сатты Муса агайга Сёма, әбинең күзләрен тутырып, аңа карап торуыннан да тарсынмыйча. Аның болай да вакытлы-вакытсыз йокысыннан уяныруга, әле җитмәсә, төн уртасында нәрсәдер хәл итеп утырырга мәҗбүр булуы, алай гына да түгел, үзенә дә сирәк эләгә торган җылы урынын кем белгәндер бүлешергә туры килүе өчен ачуы чыккан иде, шуңа да бу әллә хәтерен югалткан, әллә бөтенләй зиһенен җуйган карчыктан тизрәк котыласы килә иде.

– Аларны чакырырга беркайчан да соң түгел... Рәшәткәле машинада кунак итәргә алып китмиләр. Хәер, үзең дә беләсең анда ничек каршы алганнарын, – диде Муса агай Сёманың канәгатьсезлегенә каршы. – Ә хәзер тор әйдә, әбине утырт. Күрмисеңмени, көзге яфрак кебек калтырап тора...

Сёма теләмичә генә бәләкәй сәкенең аяк очына торып утырды. Тагын да ныграк җәлләтер өчение, янындагы мәчене алып, куенына салды. Аның балаларча кылануы, күрәсең, әбигә дә тәэсир итте. Ул да җәһәт кенә Сёма янына килеп, аны тынычландырырга ашыкты:

– Улым, менә безнең якка кайтучы берәрсе табылса, бергә кайтырбыз, яме? Җае чыгуга кайтырбыз, озакламабыз, – дигән булды.

Сёма әбигә кырын күз белән генә карап алды да мәчесен тагын да ныграк кочагына кысты һәм:

– Кая кайтасын беләме соң ул? Каян килгән? Чакыр дим бит тиешле кешеләрне, әби белән берәр хәл булса, башыңнан сыйпамаслар. Ә болай үзеңә проблемалар гына әзерлисең, – дип, Муса агайны тагын үгетләргә тотынды.

Муса агай әбигә чәй әзерли иде, ул сукбай киңәшен ишетмәгәндәй, бер сүз дә җавап кайтармады, май ягып, өстенә сыр телеме дә кисеп куелган бутербродларын биштәреннән алып, тәлинкәгә тезде.

Аның каравы әби үзенең кем икәнен белмәсә дә, колакка сизгер, сүзгә оста, җор телле булып чыкты.

– Алар килсә, иң элек мине түгел, сине алып китә. Үз гомеремдә эне дә урлаган кеше түгелмен, шулай булгач, монда син – карак! Үз гаебеңне миңа аударырга утырма, – дип, Сёманың авызын япты.

– Минме карак? – дип, нахакка рәнҗетелгән кеше кебек яклау эзләп, Муса агайга күзләрен мөлдерәтте Сёма һәм акланган кебек күңелен бушата башлады:

– Тоталар да бөтен караклыкны миннән күрәләр, маңгаема карак дип язып куйганнармыни? Әллә минем энә урлаганым бармы? Менә, Муса агай, син мине кайчаннан бирле беләсең? Караклыкта тотылганым бармы? Урлаша белсәм, монда утырмас идем әле. Үз вакытында урлашырга намусым кушмады, шул вакытта өйрәнгән булсам, бүген монда балавыз сыгарга калыр идемме? – дип, тавышын бөтенләй җебетеп агызды сукбай. Муса агай исә Сёманың гадәтен белгәнгә, аңа «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, сүзен әйтеп бетерергә мөмкинлек кенә бирде. Булмәдә хисләр куеруын сизгән әби исә Сёманы җәлләп елап җибәрде.

Ахыры бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына язылы

П2435 – җомга саны
512 сум 70 тиен
П2409 – атнага дүрт тапкыр чыга
1227 сум 30 тиен

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июненә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

Адрес: Салих Батыев ур., 1 йорт

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

Реклама 18+



Әз-мәз мәзәк

– Мине әнием кояш дип атый. Чөнки миңа карарга куркыныч.

* * *

Телевизорга эләгәсең килсә, еракка китмә, ерактан әләктерү авыр.

* * *

Әгәр дә машинагызга психолог килеп бәрелсә, аны гаепле итү бик авыр булыр. Барына да сезнең балачак комплекслары гаепле булачак.

* * *

Кыз үзенең сөйгәненең фотосын туганнарына күрсәткәч, аларның һәркайсы ни өчендер болай ди: «Нәрсә диим инде… Иң мөһиме, бәхетле булыгыз».

* * *

– Сез Рөстәм белән аерылышкансыз икән ич. Нәрсә булды?
– Башыбыздагы тараканнар бер-берсенә туры килмәделәр.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Максат, кумир, аш, Сарман, әләк, Али, иннек, Оле, как, имза, ки, су, шук, Мәккәсәрә, хаҗ, бина, Фәрит, бура, Да, кар, Рабит, Ада, Илсур, Арас, әнис, Баскан.

Вертикаль: ксерокс, хәбәр, Буа, Лаума, Ан, Мрожек, әҗер, Бари, мим, Адидас, ара, Илсаф, Атас, си, Фирзәр, иза, әби, талант, итек, Сак, Шәле, куян, азу, кикрик, анар, рун.

Беләсең килсә…

1 Казан метросы ничәнче елда ачылды?
а) 2003;
б) 2005;
в) 2007.

2 Дөньядагы иң зур кимерүче хайван нинди?
а) дикобраз;
б) капибара;
в) чупакабра.

3 «ЛуАЗ-969» машинасын халыкта ничек дип йөртәләр иде?
а) Карабас-Барабас;
б) Фантомас;
в) Тиктормас.

4 Мәскәүнең иң кыска урамы нинди?
а) Венецианов урамы;
б) Кече Арбат;
в) Банк тыкрыгы.

Җаваплар: 1.б); 2.б); 3.б); 4.а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 269

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрրирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+